25. Уровень расчетной бюджетной обеспеченности i-го сельского поселения определяется как соотношение его условного налогового потенциала к аналогичному показателю, рассчитанному по всем сельским поселениям, в расчете на одного жителя, с учетом объективных факторов и условий, влияющих на стоимость предоставления бюджетных услуг, и рассчитывается по формуле:

$$БО^{i}_{расч} = \frac{УНП^{i} \times SUM^{s}_{i=1} Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{s}_{i=1} УНП^{i}},$$

где:

$БО^{i}_{расч}$ – уровень расчетной бюджетной обеспеченности i-го сельского поселения;

$ИБР^{i}$ – индекс бюджетных расходов i-го сельского поселения, рассчитываемый в соответствии с Порядком, установленным приложением 6 к настоящему Кодексу;

$УНП^{i}$ – условный налоговый потенциал i-го сельского поселения, рассчитываемый в соответствии с Порядком, установленным приложением 7 к настоящему Кодексу;

$Ч^{i}$ – численность населения i-го сельского поселения;

s – число сельских поселений в Республике Татарстан.»;

64) в пункте 8 приложения 5 слова «($БО^{i}<К$)» заменить словами «($БО^{i}_{расч} < К$)»;

65) приложение $9^2$ изложить в следующей редакции:

«Приложение $9^2$
к Бюджетному кодексу
Республики Татарстан

**Методика расчета субвенций бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях**

1. Субвенция бюджетам муниципальных районов и городских округов (далее – муниципальные образования) из бюджета Республики Татарстан предназначена для финансового обеспечения государственных гарантий

реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, финансового обеспечения дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях.

2. Настоящая Методика основана на применении норматива финансовых затрат на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях в расчете на одного обучающегося в год.

3. При расчете субвенции используется фактическая численность обучающихся в муниципальных общеобразовательных организациях по видам, направленности (профилям) образовательных программ, уровням общего образования, формам обучения по состоянию на 1 сентября года, предшествующего планируемому.

4. Общий объем субвенции на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях (S) определяется по следующей формуле:

$$S = \mathrm{SUM}_{i=1}^{45} S_i,$$

где:

$S_i$ – объем субвенции на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях i-го муниципального образования.

5. Расчет субвенции на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях для i-го муниципального образования ($S_i$)осуществляется по следующей формуле:

$$S_i = S_N + S_{SN},$$

где:

$S_N$ – объем субвенции для i-го муниципального образования на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях, рассчитываемый в отношении численности обучающихся по классам в пределах нормативной наполняемости классов;

$S_{SN}$ – объем субвенции для i-го муниципального образования на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, рассчитываемый в отношении численности обучающихся по классам, превышающей нормативную наполняемость классов.

6. Расчет объема субвенции для i-го муниципального образования на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях в отношении численности обучающихся по классам в пределах нормативной наполняемости классов осуществляется по следующей формуле:

$$S_N = \sum_{n=1}^{3}\left(R_{jcp} \times H_{ijcp}^{fn}\right)_n + \sum_{n=1}^{3}\left(R_j^{g.p.d.} \times H_{ij}^{g.p.d.}\right)_n + \sum_{n=1}^{3}\left(R_j^{d.o.} \times H_{ij}^{f.d.o.}\right)_n + \\ + \sum_{n=1}^{3}\left(R_j^{e.} \times H_{ij}^{e.}\right)_n + \sum_{n=1}^{3}\left(R_j^{i.} \times H_{ij}^{i.}\right)_n ,$$

где:

$R_{jcp}$, $R_j^{i.}$, $R_j^{g.p.d.}$, $R_j^{e.}$, $R_j^{d.o.}$ – нормативы финансовых затрат соответственно на реализацию основных общеобразовательных программ (программ начального общего, основного общего, среднего общего образования), с учетом получения образования в форме индивидуального обучения, обучения в группах продленного дня, обучения в форме экстерната, на реализацию дополнительных образовательных программ в расчете на одного обучающегося j-й муниципальной общеобразовательной организации;

$H_{ijcp}^{fn}$, $H_{ij}^{i.}$, $H_{ij}^{g.p.d.}$, $H_{ij}^{e.}$, $H_{ij}^{f.d.o.}$ – фактическая численность обучающихся в классах в пределах нормативной наполняемости классов соответственно по основным общеобразовательным программам (программам начального общего, основного общего, среднего общего образования), с учетом численности

обучающихся, получающих образование в форме индивидуального обучения, обучения в группах продленного дня, обучения в форме экстерната, по дополнительным образовательным программам j-й муниципальной общеобразовательной организации на территории i-го муниципального образования;

n – уровень общего образования;

c – вид класса;

p – профиль обучения.

7. Расчет объема субвенции для i-го муниципального образования на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях в отношении численности обучающихся по классам, превышающей нормативную наполняемость классов, осуществляется по следующей формуле:

$$S_{SN} = \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(k \times \left(R_{jcp} \times \left(H^{f}_{ijcp} - H^{nm}_{ijcp}\right)\right)\right)_{n},$$

где:

$R_{jcp}$ – нормативы финансовых затрат на реализацию основных общеобразовательных программ в расчете на одного обучающегося j-й муниципальной общеобразовательной организации;

$H^{f}_{ijcp}$ – фактическая численность обучающихся в классах по основным общеобразовательным программам j-й муниципальной общеобразовательной организации на территории i-го муниципального образования;

$H^{nm}_{ijcp}$ – численность обучающихся в классах в соответствии с нормативной наполняемостью классов по основным общеобразовательным программам j-й муниципальной общеобразовательной организации на территории i-го муниципального образования;

k – коэффициент финансового обеспечения;

n – уровень общего образования;

c – вид класса;

p – профиль обучения.

8. Нормативы финансовых затрат на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях устанавливаются законом Республики Татарстан.

9. Методические рекомендации по расчету нормативов финансовых затрат на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение

общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях, коэффициент финансового обеспечения устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

10. Распределение субвенции местным бюджетам из бюджета Республики Татарстан на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного начального общего, основного общего, среднего общего образования в муниципальных общеобразовательных организациях, обеспечение дополнительного образования детей в муниципальных общеобразовательных организациях по муниципальным образованиям утверждается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.»;

66) приложение $9^{2.1}$ изложить в следующей редакции:

«Приложение $9^{2.1}$<br>к Бюджетному кодексу<br>Республики Татарстан

**Методика расчета субвенций бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях, реализующих программы дошкольного образования**

1. Субвенция бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан предназначена для финансового обеспечения государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях, реализующих программы дошкольного образования (далее – муниципальные образовательные организации).

2. Настоящая Методика основана на применении норматива финансовых затрат на реализацию образовательных программ дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях в расчете на одного воспитанника в год.

3. При расчете субвенции используется фактическая численность воспитанников, не превышающая предельную наполняемость групп, по категориям, возрастному составу воспитанников муниципальных образовательных организаций по состоянию на 1 сентября года, предшествующего планируемому.

4. Общий объем субвенции на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях ($S$) определяется по следующей формуле:

$$S = \sum_{i=1}^{45} S_i \ ,$$

где:

$S_i$ – объем субвенции на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях i-го муниципального образования.

5. Объем субвенции для i-го муниципального образования определяется по следующей формуле:

$$Si = \sum_{z=1}^{2} \left(R_{txy}^{ob} \times H_{itxy}^{ob}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R_{txy}^{ozd} \times H_{itxy}^{ozd}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R_{qtxy}^{komp} \times H_{iqtxy}^{komp}\right) +$$

$$+ \sum_{z=1}^{2} \left(R_{txy}^{mds} \times G_{itxy}^{mds}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R_{qtxy}^{komb} \times H_{iqtxy}^{komb}\right),$$

где:

$R_{txy}^{ob}, R_{txy}^{ozd}, R_{qtxy}^{komp}, R_{txy}^{mds}, R_{qtxy}^{komb}$ – нормативы финансовых затрат на реализацию образовательных программ дошкольного образования в расчете на одного воспитанника соответственно в группах общеразвивающей направленности, оздоровительной направленности, компенсирующей направленности, групп малокомплектных детских садов, групп комбинированной направленности;

$H_{itxy}^{ob}, H_{itxy}^{ozd}, H_{iqtxy}^{komp}, H_{iqtxy}^{komb}$ – численность воспитанников, обучающихся по образовательным программам дошкольного образования соответственно в группах общеразвивающей направленности, оздоровительной направленности, компенсирующей направленности, комбинированной направленности, определяемая в соответствии с пунктом 3 настоящей Методики, в i-м муниципальном образовании;

$G_{itxy}^{mds}$ – количество групп малокомплектной дошкольной образовательной организации i-го муниципального образования;

t – территориальное расположение муниципальной образовательной организации (городская, сельская местность);

x – количество рабочих дней группы в муниципальной образовательной организации;

y – продолжительность пребывания детей в группе муниципальной образовательной организации;

z – возрастной состав воспитанников в группе муниципальной образовательной организации;

ob – группы общеразвивающей направленности;

ozd – группы оздоровительной направленности;

komp – группы компенсирующей направленности;

mds – малокомплектные детские сады;

komb – группы комбинированной направленности;

q – категория (по заболеваниям) воспитанников в группах компенсирующей и комбинированной направленностей муниципальной образовательной организации.

6. Нормативы финансовых затрат на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях устанавливаются законом Республики Татарстан.

7. Методические рекомендации по расчету нормативов финансовых затрат на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан.

8. Распределение субвенции местным бюджетам из бюджета Республики Татарстан на обеспечение государственных гарантий реализации прав на получение общедоступного и бесплатного дошкольного образования в муниципальных образовательных организациях по муниципальным образованиям утверждается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период.»;

67) в приложении $9^3$:

а) в пункте 1 слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)», дополнить словами «(далее – государственные полномочия)»;

б) дополнить пунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Общий объем субвенций определяется по формуле:

$$C_{svod} = \sum_{i=1}^{n} C_{i\ присяжн.}$$

где:

$C_{svod}$ – общий объем субвенций бюджетам муниципальных районов и городских округов для осуществления государственных полномочий;

$C_{i\ присяжн.}$ – объем субвенций i-му муниципальному образованию для осуществления государственных полномочий;

n – число муниципальных образований, наделенных государственными полномочиями.»;

в) в пункте 2:

в абзаце первом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

в абзаце четвертом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

в абзаце пятом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

в абзаце восьмом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

абзац восемнадцатый изложить в следующей редакции:

«Чi – расчетное число граждан, подлежащих включению в списки кандидатов в присяжные заседатели по заявкам председателей судов в i-м муниципальном образовании либо утративших право быть присяжными заседателями в i-м муниципальном образовании (в случае изменения и дополнения списков);»;

в абзаце тридцатом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

в абзаце тридцать четвертом слово «(изменению)» заменить словами «(изменению, дополнению)»;

абзац тридцать седьмой изложить в следующей редакции:

«$Ci$ присяжн $= C\ svod$ / $Csvod$ уточн.$\times$ $Ci$ уточн.,»;

абзац тридцать девятый признать утратившим силу;

абзац сороковой изложить в следующей редакции:

«$Csvod$ уточн. – уточненная потребность в субвенциях по всем муниципальным районам и городским округам.»;

68) приложение 10 признать утратившим силу;

69) в пункте 9 приложения 12 слова «(БОj<К)» заменить словами «$(БО^{j}_{расч} < К)$».

**Статья 2**

Внести в часть 3 статьи 2 Закона Республики Татарстан от 4 июля 2009 года № 27-ЗРТ «О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений актов бюджетного законодательства Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2011, № 11 (II часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 22 (часть I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«3. До 1 января 2025 года в отношении муниципальных образований, на территории которых проводились международные спортивные соревнования, решения о проведении которых приняты Президентом Российской Федерации и

(или) Правительством Российской Федерации, в бюджетах которых доля дотаций из бюджета Республики Татарстан и (или) налоговых доходов по дополнительным нормативам отчислений в размере, не превышающем расчетного объема дотации на выравнивание бюджетной обеспеченности (части расчетного объема дотации), замененной дополнительными нормативами отчислений, в отчетном году не превышала 5 процентов объема собственных доходов местного бюджета, у которых объем муниципального долга на 1 января 2017 года составил более 100 процентов объема доходов местного бюджета без учета утвержденного объема безвозмездных поступлений и (или) поступлений налоговых доходов по дополнительным нормативам отчислений, объем муниципального долга может превысить ограничение, установленное пунктом 5 статьи 107 Бюджетного кодекса Российской Федерации, пунктом 5 статьи 31 Бюджетного кодекса Республики Татарстан, в пределах объема муниципального долга по бюджетным кредитам, реструктурированным в соответствии с законом Республики Татарстан по состоянию на 1 января текущего года. До 1 января 2025 года верхний предел муниципального долга устанавливается с соблюдением условий, указанных в настоящей части.».

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункт 8, абзацы двенадцатый – четырнадцатый, шестнадцатый, семнадцатый, двадцать первый и двадцать второй пункта 12, пункт 13, абзацы третий – шестой и десятый пункта 17, абзацы второй – десятый пункта 19, абзацы третий – восьмой пункта 21, пункты 25 и 26 статьи 1 и статья 2 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2020 года.

3. Пункт 61 статьи 1 настоящего Закона вступает в силу с 1 июля 2020 года.

4. Подпункты «в» и «д» пункта 7, абзацы пятый и шестой пункта 14, пункт 22 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2021 года.

5. Положения абзацев шестнадцатого и семнадцатого статьи 4, пункта 2 статьи 5, статей 15 и 16, пунктов 1, 2, 4 и 7 статьи 25, статьи 26, пунктов $3^{1}$ и $3^{2}$ статьи 27, пунктов 1, 2, 4 – 7 статьи 29, статьи $29^{1}$, пунктов 1 и 2 статьи $29^{3}$, пунктов 1 – 6 статьи 31, статей $31^{1.1}$, $31^{1.3}$, 32, 41, 43, 44, $44^{1}$, $44^{2}$, $44^{2.1}$, $44^{2.2}$, $44^{4}$, $44^{5}$, $44^{6}$, $44^{8}$, $44^{9}$, $44^{10}$, $44^{11}$, $44^{13}$ и 47, абзаца десятого статьи 49, пункта 4 статьи 55, абзаца восьмого пункта 4 статьи 61, абзаца восьмого пункта 3 статьи 77, приложений 1, 2, $9^{2}$, $9^{2.1}$, $9^{3}$ и 12 Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) применяются к правоотношениям, возникающим при составлении, утверждении и исполнении бюджетов, начиная с бюджетов на 2020 год и на плановый период 2021 и 2022 годов.

6. Положения пунктов 11, 14 – 16 и 19 статьи 29, пункта 7 статьи 31, пунктов 5 – 7 и 9 статьи $31^{1}$ Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) применяются к правоотношениям, возникающим

при составлении, утверждении и исполнении бюджетов, начиная с бюджетов на 2021 год и на плановый период 2022 и 2023 годов.

7. Положения пунктов 12 и 17 статьи 29 Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) в части согласования Республикой Татарстан (муниципальным образованием) программ заимствований и гарантий, а также изменений в эти программы применяются к правоотношениям, возникающим при составлении, утверждении и исполнении бюджетов, начиная с бюджетов на 2021 год и на плановый период 2022 и 2023 годов.

8. Положения пунктов 12 и 17 статьи 29 Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) в части права осуществления заимствований и предоставления гарантий Республикой Татарстан (муниципальным образованием) применяются с 1 января 2021 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
27 сентября 2019 года
№ 71-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче абзацында «һәм муниципаль хисаплашуларны» сүзләрен «(муниципаль хисаплашуларны)» сүзләренә, «һәм муниципаль бурычны» сүзләрен «(муниципаль бурычны)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 статьяда:
а) унбишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
б) түбәндәге эчтәлекле яңа уналтынчы абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле аерым салым булмаган керемнәрдән җирле бюджетларга керемнәр түләү нормативларын билгеләү;»;
в) уналтынчы абзацны унҗиденче абзац дип санарга;

3) 5 статьяда:

а) 1 пунктның сигезенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль районнар бюджетларына күчерелергә тиешле аерым салым булмаган керемнәрдән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына керемнәр түләү нормативларын билгеләү;»;

өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга һәм аны үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче һәм алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

4) 15 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 58 статьясында каралган салым булмаган керемнәр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тулысынча яисә өлешчә Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган тәртиптә тиешле җирле бюджетларга тапшырылырга мөмкин.»;

б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга;

5) 16 статьяның 3 пунктында:

а) беренче абзацта «барлык җирлекләре өчен» сүзләрен «барлык шәһәр җирлекләре өчен» сүзләренә, «җирлекләр бюджетларына» сүзләрен «шәһәр җирлекләре бюджетларына» сүзләренә алмаштырырга, «җирле салымнардан» сүзләреннән соң «, салым булмаган керемнәрдән» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «җирле салымнардан» сүзләреннән соң «, салым булмаган керемнәрдән» сүзләрен өстәргә;

6) түбәндәге эчтәлекле $24^1$ һәм $24^2$ статьялар өстәргә:

«$24^1$ статья. **Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр**

1. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмә нигезендә билгеләнгән датага бурычлы тарафыннан түләнергә тиешле акчалар суммасы Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч булып тора.

2. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр Татарстан Республикасының финанс активларын формалаштыра.

3. Акчалата йөкләмәләр буенча Татарстан Республикасы алдындагы бурычларны исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) һәм мондый йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган алыш-бирешләрне исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләп хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән тиешле орган яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Әгәр шартнамәдә башкача билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр тиешле сумманы Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына күчергән көннән үтәлгән дип санала.

$24^2$ статья. **Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне реструктуризацияләү һәм алар буенча бурычларны җайга салуның башка ысуллары**

1. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр (акчалата йөкләмәләр буенча бурыч) түбәндәге ысуллар белән җайга салынырга мөмкин:

1) килешүгә нигезләнеп, акчалата йөкләмәне (аның буенча бурычны) үтәү срокларын үзгәртүгә (шул исәптән кичектереп тору яисә өлешләп түләү юлы белән) бәйле рәвештә акчалата йөкләмәләрне үтәү шартларын үзгәртү, акчалата чаралардан һәм (яисә) башка түләүләрдән файдаланган өчен процентлар күләмен үзгәртү (алга таба – Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәне (акчалата йөкләмә буенча бурычны) реструктуризацияләү);

2) килешүгә нигезләнеп, шул ук затлар арасында башлангыч йөкләмәне башка предметны яисә үтәү ысулын күздә тота торган башка йөкләмә белән алмаштырып туктату (алга таба – Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәне яңарту);

3) Россия Федерациясе бюджет һәм (яисә) граждан законнарында каралган башка ысуллар.

2. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) җайга салу мөмкинлеге, ысуллары һәм төп шартлары Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) реструктуризацияләү кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы актлары белән билгеләнә, алар Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) реструктуризацияләүнең өстәмә шартларын, шул исәптән Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) реструктуризацияләү хокукына ия булган бурычлылар туры килергә тиеш булган критерийларны билгеләргә хокуклы.

4. Суд эшчәнлеге турында, башкарма эшчәнлек һәм бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган ысуллар белән Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны җайга салу шартлары билгеләнә торган ризалык килешүләре төзү турында карарлар кабул итәргә хокуклы.

5. Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәне (акчалата йөкләмә буенча бурычны) реструктуризацияләү, шулай ук Татарстан Республикасы алдында яңа акчалата йөкләмә барлыкка килүгә китерә торган Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәне яңарту, кредитор – Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурычлының вакыты чыккан (җайга салынмаган) бурычы, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау шартларыннан (таләпләрдән) тыш, Россия Федерациясе Бюджет кодексында бюджет кредитларына карата билгеләнгән таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы алдында реструктурлаштырылган акчалата йөкләмәләргә, шулай ук Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләрне яңарту нәтиҗәсендә барлыкка килгән Татарстан Республикасы алдындагы акчалата йөкләмәләргә Россия Федерациясе Бюджет кодексының һәм әлеге Кодексның гавами-хокукый берәмлек (Татарстан Республикасы) алдындагы акчалата йөкләмәләре турындагы нигезләмәләре кагыла.»;

7) 25 статьяда:

а) 1 пунктта:

өченче абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил банкларының Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән һәм кайтарылган кредитлары арасындагы аерма;»;

алтынчы абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктта:

өченче абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче һәм бишенче абзацлар өстәргә:

«чит ил валютасында халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән һәм түләнгән кредитлар арасындагы аерма;

максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында бирелгән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан алынган һәм түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;»;

дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы – сигезенче абзацлар дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме;»;

җиденче абзацны унынчы абзац дип санарга;

в) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә Татарстан Республикасы бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм финанс хисабы елы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән күләмдә агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен кимәтә торган түләүләрне гамәлгә ашыруга җибәрелә.»;

г) 4 пунктта:

өченче абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «алынган» сүзен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче һәм уникенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле бюджетның агымдагы финанс елы башына калган акчалары:

муниципаль юллар фондының финанс хисабы елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юллар фонды бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә, шулай ук муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы хокукый актында билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплау өчен һәм муниципаль берәмлек исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартларына ярашлы рәвештә финанс хисабы елында түләнергә тиеш булган товарлар китергән, эшләр башкарган, хезмәтләр күрсәткән өчен түләүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен, финанс хисабы елында субсидия алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән әлеге субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган юридик затларга, җирле бюджет турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарында билгеләнгән очракларда, күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелергә мөмкин;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә муниципаль берәмлек бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, хисаплашуларның гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм финанс хисабы елы йомгаклары буенча муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән күләмдә агымдагы финанс

елында муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен киметә торган түләүләрне гамәлгә ашыруга җибәрелә.»;

е) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Җирле бюджет кытлыгын тышкы финанслау чыганаклары составына түбәндәгеләр керә:

максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән һәм муниципаль берәмлек тарафыннан түләнгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан чит ил валютасында бирелгән һәм муниципаль гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме.»;

8) 26 статьяда:

а) 2 пунктта:

2 пунктчада «башка бюджетларыннан» сүзләре үзгәрешсез кала;

3 пунктчада «алынган» сүзләрен «җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Россия Федерациясе Бюджет кодексы гамәлгә кергәнче барлыкка килгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт бурычына караган башка бурыч йөкләмәләре.»;

алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга һәм аны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктның 2 – 5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) кредит оешмаларыннан, чит ил банкларыннан һәм халыкара финанс оешмаларыннан Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;

3) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Татарстан Республикасы бюджетына җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

4) Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләр күләме;

5) Татарстан Республикасының түләнмәгән башка бурыч йөкләмәләре күләме.»;

в) 4 пунктта:

2 пунктчада «Татарстан Республикасы тарафыннан алынган» сүзләрен «Татарстан Республикасы тарафыннан кредит оешмаларыннан, халыкара финанс оешмаларыннан һәм чит ил банкларыннан җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «кредитлары буенча» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе валютасындагы йөкләмәләр буенча» сүзләрен өстәргә;

4 пунктчада «, Татарстан Республикасы тарафыннан бирелгән» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Татарстан Республикасының Россия Федерациясе валютасында башка түләнмәгән бурыч йөкләмәләре күләме.»;

г) 5 пунктта:

2 пунктчада «Татарстан Республикасы тарафыннан алынган» сүзләрен «Татарстан Республикасы тарафыннан халыкара финанс оешмаларыннан һәм чит ил банкларыннан җәлеп ителгән» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләр күләме;»;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пунктча өстәргә:

«$3^1$) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында чит ил валютасында Россия Федерациясеннән Татарстан Республикасы тарафыннан җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасының чит ил валютасында башка түләнмәгән бурыч йөкләмәләре күләме.»;

9) $26^1$ статьяның 1 пунктында:

а) «яисә Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе вакыты беткән булса һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115 статьясында һәм әлеге Кодексның 37 статьясында каралган башка очракларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләре Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен туктатуга нигез булып тора торган вакыйгалар (хәлләр) барлыкка килгәндә тулысынча туктатылган дип санала һәм күрсәтелгән вакыйгалар (хәлләр) барлыкка килгән (барлыкка килү турында белешмәләр алган) саен Татарстан Республикасы дәүләт бурычыннан юкка чыгарыла.»;

10) 27 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлек бурыч йөкләмәләре түбәндәгеләр буенча йөкләмәләр рәвешендә булырга мөмкин:

1) муниципаль берәмлек кыйммәтле кәгазьләре (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр);

2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

3) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында чит ил валютасында Россия Федерациясеннән җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

4) кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында муниципаль берәмлек тарафыннан җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

5) муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе валютасында белдерелгән гарантияләре (муниципаль гарантияләр);

6) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында чит ил валютасында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән муниципаль гарантияләр;

7) әлеге Кодекс гамәлгә кергәнче барлыкка килгән һәм муниципаль бурычка караган башка бурыч йөкләмәләре.»;

б) 3 пунктта:

2 пунктчада «Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан» сүзләрен өстәргә;

3 пунктчада «муниципаль берәмлек тарафыннан алынган» сүзләрен «муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада «(күрсәтелгәннәрдән гайре)» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ һәм $3^2$ пунктлар өстәргә:

«$3^1$. Эчке муниципаль бурыч күләменә түбәндәгеләр керә:

1) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) җирле бюджетка Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп ителгән, йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән, йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе валютасында башка түләнмәгән бурыч йөкләмәләре күләме.

$3^2$. Муниципаль тышкы бурыч күләменә түбәндәгеләр керә:

1) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында муниципаль берәмлек тарафыннан Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

2) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында муниципаль берәмлек тарафыннан Россия Федерациясенә чит ил валютасында бирелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме.»;

г) 5 пунктта «муниципаль берәмлек башкарма-боеру органы (җирле администрация)» сүзләрен «җирле администрация (муниципаль берәмлек башкарма-боеру органы)» сүзләренә алмаштырырга;

11) $27^1$ статьяның 1 пунктында:

а) «яисә муниципаль гарантия вакыты узган булса һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115 статьясында һәм әлеге Кодексның 37 статьясында каралган башка очракларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча бурыч йөкләмәләре муниципаль гарантияләрне туктатуга нигез булып тора торган вакыйгалар (хәлләр) барлыкка килгәндә тулысынча туктатылган

дип санала һәм күрсәтелгән вакыйгалар (хәлләр) барлыкка килгән (барлыкка килү турында белешмәләр алган) саен муниципаль бурычтан юкка чыгарыла.»;

12) 29 һәм 29[1] статьяларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт хисаплашулары (муниципаль хисаплашулар)**

1. Татарстан Республикасының эчке дәүләт хисаплашулары дигәндә, Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан, кредит оешмаларыннан, халыкара финанс оешмаларыннан һәм чит ил банкларыннан кредитлар рәвешендә Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы бюджетына заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла, алар буенча Татарстан Республикасының заемчы буларак Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

2. Эчке муниципаль хисаплашулар дигәндә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә җирле бюджетка муниципаль берәмлек исеменнән заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла, алар буенча муниципаль берәмлекнең заемчы буларак бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

3. Татарстан Республикасының эчке дәүләт хисаплашулары һәм эчке муниципаль хисаплашулар Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет кытлыгын финанслау, шулай ук Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлек бурыч йөкләмәләрен түләү, финанс елы дәвамында тиешенчә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет счетларында калган акчаларны тулыландыру максатларында гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары дигәндә, Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе тарафыннан максатчан чит ил кредитларын файдалану кысаларында федераль бюджеттан кредитлар рәвешендә, шулай ук халыкара финанс оешмаларыннан һәм чит ил банкларыннан Татарстан Республикасы бюджетына заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла, алар буенча Татарстан Республикасының заемчы буларак чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

5. Тышкы муниципаль хисаплашулар дигәндә Россия Федерациясе тарафыннан максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында муниципаль берәмлек исеменнән федераль бюджеттан җирле бюджетка кредитлар җәлеп итү аңлашыла, алар буенча Россия Федерациясе алдында чит ил валютасында белдерелгән муниципаль берәмлек бурыч йөкләмәләре барлыкка килә.

6. Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау, шулай ук Татарстан Республикасының чит ил валютасында белдерелгән дәүләт бурыч йөкләмәләрен түләү максатларында гамәлгә ашырыла.

7. Муниципаль тышкы хисаплашулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең тышкы дәүләт хисаплашулары программасына кертелгән проектларны финанслау максатларында гамәлгә ашырыла.

8. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашуларын гамәлгә ашыру хокукына, әгәр мондый хокук Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бирелмәсә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ия була.

9. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль хисаплашуларны гамәлгә ашыру хокукына җирле администрация (муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы) ия була.

10. Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен (муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне) урнаштыру Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) тарафыннан түбәндәге шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырыла:

1) Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлар булмау;

2) Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) бер яисә берничә рейтинг гамәлен башкаручы юридик затлардан алынган кредит рейтингы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән ким булмау, мондый юридик затлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

11. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклыгының уртача дәрәҗәсенә ия булган заемчылар төркеменә кергән очракта, Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 5 пунктында каралган бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләрен арттыруга китерә, Татарстан Республикасын (муниципаль берәмлекне) бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кадәр төшерүгә китерә торган күләмнәрдә дәүләт (муниципаль) хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, дәүләт (муниципаль) гарантияләрен бирергә хокуклы түгел.

12. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, бары тик чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашулары, дәүләт гарантияләре программаларын (чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программаларын), шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне Россия Федерациясе Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы) белән килештергән очракта, дәүләт

(муниципаль) хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, дәүләт (муниципаль) гарантияләрен бирергә хокуклы.

13. Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекнең эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар программаларын, муниципаль гарантияләрен, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килештерүдән баш тарту өчен муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 19 пункты, 106 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары һәм $107^1$ статьясындагы 12 пункты, әлеге Кодексның әлеге статьядагы 11 пункты, $29^3$ статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары һәм $31^1$ статьясындагы 9 пункты таләпләрен үтәмәве нигез булып тора.

14. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклылыгының Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 5 пунктында каралган күрсәткечләрен арттыруга китерә торган күләмнәрдә дәүләт (муниципаль) хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, дәүләт (муниципаль) гарантияләрен бирергә хокуклы түгел.

15. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, эчке дәүләт (муниципаль) хисаплашуларын бары тик Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) кыйммәтле кәгазьләрен рефинанслау максатларында гына, кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә һәм Татарстан Республикасының (муниципаль берәмлекнең) кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 9 пунктында һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясындагы 7 пунктында каралган Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) түләү сәләтен торгызу планы кысаларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән максатчан бюджет кредитлары рәвешендә гамәлгә ашырырга хокуклы.

16. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән очракта, дәүләт (муниципаль) тышкы хисаплашуларны гамәлгә ашырырга һәм дәүләт (муниципаль) гарантияләрен чит ил валютасында бирергә хокуксыз була.

17. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек), Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч тотрыклыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кергән очракта, Россия Федерациясе валютасында чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы

эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашулары, дәүләт гарантияләре программаларын (Россия Федерациясе валютасында чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программаларын), шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне бары тик Россия Федерациясе Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы) белән килештергән очракта гына, дәүләт (муниципаль) хисаплашуларын гамәлгә ашырырга, дәүләт (муниципаль) гарантияләрен бирергә хокуклы.

18. Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясы һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекнең эчке муниципаль хисаплашулар программаларын, муниципаль гарантияләрен, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килештерүдән баш тарту өчен муниципаль берәмлекнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 23 – 25 пунктлары, 106 статьясындагы 2 – 4 пунктлары һәм $107^1$ статьясындагы 11, 12 пунктлары, әлеге Кодексның шушы статьясындагы 14 –16 пунктлары, $29^3$ статьясындагы 2 – 4 пунктлары һәм $31^1$ статьясындагы 9 пункты таләпләрен үтәмәве нигез булып тора.

19. Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 9 пунктында һәм әлеге Кодексның $31^1$ статьясындагы 7 пунктында каралган муниципаль берәмлекнең түләү сәләтен торгызу планы кысаларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән максатчан бюджет кредитлары буенча муниципаль берәмлек йөкләмәләренә реструктуризацияләү уздыру рөхсәт ителми.

### $29^1$ статья. **Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр тарафыннан чит ил валютасында хисаплашулар һәм гарантияләр бирү үзенчәлекләре**

1. Тышкы дәүләт хисаплашулары Татарстан Республикасы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә шушы статьяның 2 – 4 пунктлары нигезләмәләрен үтәгәндә гамәлгә ашырыла.

2. Номиналь бәясе чит ил валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру номиналь бәясе чит ил валютасында күрсәтелгән Россия Федерациясе дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру өстенлеген саклаганда гамәлгә ашырыла. Номиналь бәясе чит ил валютасында күрсәтелгән Татарстан Республикасының дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру буенча операцияләр уздыру сроклары Россия Федерациясе Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы, чираттагы финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булып тормаса, чираттагы финанс елыннан башлап Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау максатларында, шулай ук чит ил валютасында белдерелгән

Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү өчен, түбәндәге шартларны үтәгәндә, тышкы дәүләт хисаплашуларын гамәлгә ашырырга хокуклы:

1) Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурыч булмау;

2) Татарстан Республикасының бер яисә берничә рейтинг гамәлен башкаручы юридик затлардан алынган кредит рейтингы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән ким булмау, мондый юридик затлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы, чираттагы финанс елында Россия Федерациясе субъектларының бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы булып торса, чираттагы финанс елыннан башлап, Татарстан Республикасының чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләрен түләү өчен, түбәндәге шартларны үтәгәндә, тышкы дәүләт хисаплашуларын гамәлгә ашырырга хокуклы:

1) Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурыч булмау;

2) Татарстан Республикасының бер яисә берничә рейтинг гамәлен башкаручы юридик затлардан алынган кредит рейтингы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән ким булмау, мондый юридик затлар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

3) агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары күләме, чит ил валютасында белдерелгән гарантияләр буенча йөкләмәләрне исәпкә алмыйча, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының ел башына тышкы дәүләт бурычын түләү буенча йөкләмәләр күләменнән артмау.

5. Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләр Россия Федерациясеннән чит ил валютасындагы хисаплашуларны гамәлгә ашырырга, Россия Федерациясеннән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты һәм әлеге Кодексның 29 статьясындагы 16 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитлары акчаларын Россия Федерациясе тарафыннан куллану кысаларында гына чит ил валютасында гарантияләр бирергә хокуклы.

6. Әлеге статьяның 3 пунктындагы 2 пунктчасы һәм 4 пунктындагы 2 һәм 3 пунктчалары нигезләмәләре Россия Федерациясе тарафыннан җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитлары акчаларын файдалану кысаларында Россия Федерациясеннән хисаплашуларны гамәлгә ашырган, шулай ук күрсәтелгән кредитларны өченче затлар йөкләмәләре буенча чит ил валютасында куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында бирелгән очракта исәпкә алынмый.»;

13) $29^2$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

14) $29^3$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$29^3$ статья. **Татарстан Республикасы хисаплашуларының (муниципаль хисаплашуларның) иң чик күләме**

1. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы хисаплашуларының (муниципаль хисаплашуларның) иң чик күләме дигәндә тиешле финанс елына Татарстан Республикасы эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашулары программалары (эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар программалары) буенча Татарстан Республикасы бюджетына (җирле бюджетка) акча җәлеп итүнең җыелма күләме аңлашыла.

2. Татарстан Республикасы бюджетына (җирле бюджетка) акча җәлеп итү күләмнәре чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы дәүләт хисаплашулары программалары (чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар программалары) белән билгеләнә, һәм тиешле финанс елында җәлеп ителгән акчаларның гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгын финанслауга җибәрелә торган акчаларның һәм, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары, әлеге Кодексның 29 һәм 29[1] статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (җирле бюджет турында карар) белән Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) бурыч йөкләмәләрен түләүнең тиешле финанс елына расланган күләменең гомуми суммасыннан артмаска тиеш.

3. Финанс хисабы елында Татарстан Республикасы хисаплашуларының гомуми суммасы Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм финанс хисабы елы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, агымдагы елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының күрсәтелгән арттыру суммасында барлыкка килгән күләме Россия Федерациясе Бюджет кодексының 95 статьясындагы 3 пунктында һәм әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктында каралган максатларга, агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп, юнәлдерелергә тиеш.

4. Финанс хисабы елында муниципаль берәмлек хисаплашуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм финанс хисабы елы йомгаклары буенча агымдагы елның 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, күрсәтелгән арттыру суммасында җирле бюджет акчаларының калдыклары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында һәм әлеге Кодексның 25 статьясындагы 5 пунктында каралган максатларга, агымдагы финанс елына хисаплашуларның иң чик күләмен киметеп, юнәлдерелергә тиеш.»;

15) 30 статьяда:

а) исемендә «Бурычны» сүзен «Дәүләт (муниципаль) бурычын» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт (муниципаль) бурычын реструктуризацияләү дигәндә йөкләмәләрне үтәүнең (бурычларны каплау) шартларын кичектереп тору,

йөкләмәләрне үтәүне кичектереп торуга, өлешләп үтәүгә, күрсәтелгән йөкләмәләр килеп чыга торган шартнамәләрдә (килешүләрдә) һәм башка документларда каралган күләмнәрен һәм (яисә) процентларны һәм (яисә) башка түләүләрне үзгәртүгә бәйле килешүдә нигезләнгән үзгәреш аңлашыла.»;

в) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

16) 31 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31 статья. **Татарстан Республикасы эчке һәм тышкы дәүләт бурычының югары чикләре, эчке һәм тышкы муниципаль бурычның югары чикләре һәм Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең иң чик күләмнәре**

1. Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының, Татарстан Республикасының тышкы дәүләт бурычының (Татарстан Республикасының чит ил валютасында йөкләмәләре булганда) иң югары чикләре, шул исәптән Татарстан Республикасының Россия Федерациясе валютасында дәүләт гарантияләре буенча, чит ил валютасында (Татарстан Республикасының чит ил валютасында дәүләт гарантияләре буенча йөкләмәләре булган очракта) бурычының иң югары чиге билгеләнә.

2. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының җирле бюджет турында муниципаль хокукый акты (җирле бюджет турында карар) белән чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына (чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына) эчке муниципаль бурычның, тышкы муниципаль бурычның (муниципаль берәмлекнең чит ил валютасында йөкләмәләре булган очракта) иң югары чикләре, шул исәптән Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча, чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча (муниципаль берәмлекнең чит ил валютасында муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләре булган очракта) бурычның иң югары чиге билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының, Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының югары чикләре (Татарстан Республикасының чит ил валютасындагы йөкләмәләре булганда), эчке муниципаль бурычның, тышкы муниципаль бурычның (муниципаль берәмлекнең чит ил валютасындагы йөкләмәләре булганда) иң югары чикләре әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләрне үтәгәндә билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган, кире кайтарылмый торган түләүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменнән артмаска тиеш. Татарстан Республикасына карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 130 статьясындагы 4 пунктында каралган

чараларны гамәлгә ашырганда, Татарстан Республикасы дәүләт бурычы күләме, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артмаска тиеш.

5. Муниципаль бурыч күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар нигезендә расланган, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән түләүләрнең расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән артмаска тиеш. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында һәм әлеге Кодексның 44 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлек өчен бурыч күләме, кире кайтарылмый торган кертемнәрнең һәм (яисә) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең расланган күләмен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменең 50 процентыннан артмаска тиеш.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тиешле бурыч белән идарә итү кысаларында Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясында, әлеге статьяда билгеләнгән тиешле чикләүләр чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычы, муниципаль бурыч буенча өстәмә чикләүләр расларга хокуклы.

7. Татарстан Республикасы дәүләт бурычына (муниципаль бурычка) хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме түбәндәге таләпләрне үтәгәндә Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (җирле бюджет турында карар) белән раслана:

1) чираттагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы дәүләт бурычына (чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) муниципаль бурычка) хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме өлеше чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы яисә чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган тиешле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең 10 процентыннан артмаска тиеш, моңа Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар күләме керми;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында чираттагы финанс елының 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт бурычын каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча барлыкка килгән түләүләрнең еллык суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының салым, салым булмаган керемнәре һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең еллык күләменнән 20 процентка артмаска тиеш;

күрсәтелгән нисбәтне исәпләгәндә чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң киләторган елның 1 гыйнварыннан соң каплана торган бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләр суммасы исәпкә алынмый;

3) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) чираттагы финанс елының 1 гыйнварына муниципаль бурычны каплау һәм аңа хезмәт күрсәтү буенча барлыкка килгән түләүләрнең еллык суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган җирле бюджетның салым, салым булмаган керемнәре һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең еллык күләменнән 20 процентка артмаска тиеш; күрсәтелгән нисбәтне исәпләгәндә чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварыннан соң каплана торган бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда каплауга җибәрелә торган түләүләр суммасы исәпкә алынмый.»;

17) түбәндәге эчтәлекле яңа 31[1] статья өстәргә:

«31[1] статья. **Муниципаль берәмлекнең бурыч тотрыклылыгын бәяләү**

1. Муниципаль берәмлекнең бурыч тотрыклылыгын бәяләү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107[1] статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне, «Бурычның гомуми күләмендә кыска сроклы бурыч йөкләмәләре өлеше» күрсәткечен, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы карары буенча башка күрсәткечләрне кулланып гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль берәмлек Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан заемчыларның түбәндәге төркемнәренең берсенә кертелергә тиеш: бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган, бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган яисә бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган.

3. Муниципаль берәмлекләрне әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән заемчылар төркемнәренә кертү аларга, бурыч тотрыклылыгы дәрәҗәсенә карап, Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста каралган таләпләрне кую өчен нигез булып тора.

4. Әлеге статьяның 2 пунктында күрсәтелгән заемчылар төркемнәренә кертелгән муниципаль берәмлекләр исемлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елының 1 октябреннән дә соңга калмыйча төзелә.

5. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркемендәге муниципаль берәмлек Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 20 һәм 26 пунктлары һәм әлеге Кодексның 29 статьясындагы 12 һәм 17 пунктлары нигезендә чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке һәм тышкы муниципаль хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук әлеге программаларга чираттагы финанс елына һәм план чорына

(чираттагы финанс елына) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына кертелергә әзерләнгән җирле бюджет проектына кушымта булып торган үзгәрешләрне килештерү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына документлар һәм материаллар кертә.

6. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлеккә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында һәм әлеге Кодексның 44 статьясындагы 2 һәм 3 пунктларында каралган таләпләр кулланыла.

7. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлеккә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясындагы 4 пунктында һәм әлеге Кодексның 44 статьясындагы 4 пунктында каралган чаралар кулланыла, шулай ук күрсәтелгән муниципаль берәмлеккә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $168^4$ статьясындагы 2 пункты таләпләре нигезендә муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән түләү сәләтен торгызу планын раслау һәм гамәлгә ашыру бурычы йөкләнә.

8. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлек Россия Федерациясе Бюджет кодексының $107^1$ статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрнең факттагы торышына карамастан, бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган төркемнән чыкканнан соң кимендә өч ел узгач бурыч тотрыклылыгы югары дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелергә мөмкин.

9. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача яисә түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекнең бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 20 һәм 26 пунктлары һәм әлеге Кодексның 29 статьясындагы 12 һәм 17 пунктлары нигезендә агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча килештерелергә тиешле муниципаль хисаплашулар, муниципаль гарантияләр программалары белән бер үк вакытта Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бирелә.

10. Муниципаль берәмлекнең җаваплы бурыч сәясәтен гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында муниципаль берәмлекнең чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле администрация тарафыннан эшләнә торган бурыч сәясәтенең төп юнәлешләрендә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс белән әзерләү каралган түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) бурыч сәясәтен тормышка ашыру йомгаклары;

2) бурыч сәясәтенең характерын һәм юнәлешләрен билгели торган төп факторлар;

3) бурыч сәясәтенең максатлары һәм бурычлары;

4) бурыч сәясәтен тормышка ашыру алымнары;

5) муниципаль бурыч белән идарә итү барышында барлыкка килә торган бюджет өчен хәтәрләрне анализлау;

6) бюджет мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезендә башка нигезләмәләр.»;

18) $31^{1}$ статьяны $31^{1.1}$ статья дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$31^{1.1}$ статья. **Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары программасы**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында гамәлгә ашырыла һәм (яисә) каплана торган бурыч йөкләмәләре төрләре буенча Татарстан Республикасы тышкы дәүләт хисаплашулары исемлегеннән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы тышкы дәүләт хисаплашулары программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) Татарстан Республикасы бюджетына акчаларны җәлеп итү күләмнәре һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашуларын гамәлгә ашырганда бурыч йөкләмәләре төрләре буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплауның иң чик сроклары;

2) бурыч йөкләмәләре төрләре буенча чираттагы финанс елында һәм план чорында чит ил валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәре.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасының тышкы дәүләт хисаплашулары программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына кушымта булып тора.»;

19) түбәндәге эчтәлекле $31^{1.2}$ һәм $31^{1.3}$ статьялар өстәргә:

«$31^{1.2}$ статья. **Чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы**

1. Чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында, түбәндәге белешмәләрне күрсәтеп, чит ил валютасында бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең, муниципаль гарантияләрнең исемлегеннән гыйбарәт:

1) һәр юнәлеш (максат) буенча гарантияләр күләмен, гарантиянең һәр юнәлеше (максаты) буенча принципаллар категорияләрен (төркемнәрен) һәм (яисә) атамаларын күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләр һәм алар белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр валютасы;

3) гарантияләрнең гомуми күләме;

4) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);

5) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе, муниципаль гарантия Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе, муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр белдерелгән валютада бирелә һәм үтәлә.

3. Чит ил валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы бюджет турында тиешле законга (карарга) кушымта булып тора.

31[1.3] статья. **Тышкы муниципаль хисаплашулар программасы**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) тышкы муниципаль хисаплашулар программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында федераль бюджеттан җирле бюджетка чит ил валютасында җәлеп ителә торган һәм (яисә) түләнә торган бюджет кредитлары исемлегеннән гыйбарәт.

2. Тышкы муниципаль хисаплашулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) җирле бюджетка акчалар җәлеп итү күләме һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында федераль бюджеттан җирле бюджетка чит ил валютасында җәлеп ителә торган бюджет кредитлары буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплау сроклары;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) максатчан чит ил кредитларыннан файдалану кысаларында җирле бюджетка федераль бюджеттан чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча муниципаль берәмлекнең бурыч йөкләмәләрен каплау күләме.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) тышкы муниципаль хисаплашулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карарга кушымта булып тора.»;

20) 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32 статья. **Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары (эчке муниципаль хисаплашулар) программасы**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары (чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке муниципаль хисаплашулар) программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында гамәлгә ашырыла һәм (яисә) каплана торган тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча Татарстан Республикасының эчке дәүләт хисаплашулары (эчке муниципаль хисаплашулар) исемлегеннән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары (эчке муниципаль хисаплашулар) программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) Татарстан Республикасы бюджетына (җирле бюджетка) акчалар җәлеп итү күләмнәре һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын (чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) эчке муниципаль хисаплашуларны) гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча бурыч йөкләмәләрен түләүнең иң чик сроклары;

2) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт бурыч йөкләмәләрен (муниципаль бурыч йөкләмәләрен) тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча түләү күләмнәре.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары (чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) эчке муниципаль хисаплашулар) программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) тиешле бюджет турында законга (карарга) кушымта булып тора.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 статьясы, әлеге Кодексның 30 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычын (эчке муниципаль бурычны) реструктуризацияләү Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары (эчке муниципаль хисаплашулар) программасында чагылдырылмый.»;

21) түбәндәге эчтәлекле $32^1$ пункт өстәргә:

«$32^1$ статья. **Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы**

1. Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең, муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләрне күрсәтеп бирелә торган исемлегеннән гыйбарәт:

1) һәр юнәлеш (максат) буенча гарантияләр күләмен, гарантиянең һәр юнәлеше (максаты) буенча принципаллар категорияләрен (төркемнәрен) һәм (яисә) атамаларын күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләрнең гомуми күләме;

3) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);

4) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән йөкләмәләр буенча дәүләт (муниципаль) гарантияләре бары тик Россия Федерациясе валютасында гына бирелә һәм үтәлә.

Россия Федерациясе валютасындагы Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре, муниципаль гарантияләр программасы бюджет турында тиешле законга (карарга) кушымта булып тора.»;

22) 33 һәм 34 статьяларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

23) 35 статьяда:

а) исемендә «яисә муниципаль бурыч» сүзләрен «(муниципаль бурыч)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:

беренче абзацта «яисә муниципаль бурыч» сүзләрен «(муниципаль бурыч)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «яисә муниципаль бурыч» сүзләрен «(муниципаль бурыч)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «яисә муниципаль хисаплашулардан» сүзләрен «(муниципаль хисаплашулардан)» сүзләренә алмаштырырга;

24) 36 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«36 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен һәм муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыруның иң чик күләмнәре**

Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына яисә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына (чираттагы финанс елына) номиналь хакы буенча урнаштыруның иң чик күләмнәре тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан Татарстан Республикасы эчке һәм тышкы дәүләт бурычының, эчке муниципаль бурычның тиешле бюджет турындагы законда (карарда) билгеләнгән иң югары чиге нигезендә билгеләнә.»;

25) 37 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«37 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (муниципаль гарантияләр)**

1. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) шартнамәдән яисә башка алыш-бирешләрдән (төп йөкләмәдән) принципалның бенефициар каршында барлыкка килгән акча йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) принципалның йөкләмәләрен вакытыннан алда, шул исәптән принципалга аларны вакытыннан алда үтәү турында таләп куелган йә принципалның йөкләмәләрен үтәү срогы җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) килеп чыккан очракта вакытыннан алда үтәүне тәэмин итми.

3. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясенең (муниципаль гарантиянең) язма рәвеше мәҗбүри булып тора.

4. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) төп йөкләмә суммасы белдерелгән валюта белән бирелә һәм үтәлә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча гарант принципалга тәэмин иткән йөкләмәсе буенча гарантия суммасы чикләрендә субсидиар җаваплылыкка ия була.

6. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гарант исеме (тиешле гавами-хокукый берәмлек – Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек) һәм гарант исеменнән гарантия биргән орган исеме;

2) бенефициар исеме;

3) принципал исеме;

4) тәэмин ителеше өчен гарантия бирелә торган йөкләмә (төп йөкләмәнең исемен, төзелү датасын һәм номерын (булган очракта), төп йөкләмәнең гамәлдә булу срогын яисә аның буенча йөкләмәләрне үтәү срогын, яклар исемнәрен, төп йөкләмәнең башка мөһим шартларын күрсәтеп);

5) гарантия буенча гарант йөкләмәләре күләме һәм гарантиянең иң чик суммасы;

6) гарантия бирелүнең нигезе;

7) гарантиянең үз көченә керү датасы яисә гарантия үз көченә керәчәк вакыйга (шарт);

8) гарантиянең гамәлдә булу срогы;

9) гарантия очракларын билгеләү, бенефициарның гарантия үтәлешен таләп итү срогы һәм тәртибе;

10) гарантиянең чакыртып алу шартлары;

11) гарантның гарантия буенча йөкләмәләрен үтәү тәртибе;

12) гарантия тулы күләмдә яисә кайсы да булса өлешендә үтәлгәндә, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләре тулы күләмдә яисә кайсы да булса өлешендә үтәлгәндә (башка нигезләрдә туктатылганда) һәм гарантиядә билгеләнгән башка очракларда гарантиянең суммасын киметү нигезләре;

13) гарантияне туктату нигезләре;

14) төп йөкләмәнең гарант тарафыннан алдан бирелгән язма ризалыктан башка үзгәртелә алмый торган шартлары;

15) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча бенефициарга гарант тарафыннан түләнгән акчаларны каплау турында принципалга карата гарант таләбе хокукы булу яисә булмау (принципалга карата гарантның регресс таләбе, регресс);

16) Россия Федерациясе Бюджет кодексы, әлеге Кодекс, гарантның хокукый норматив актлары, гарант исеменнән гарантия биргән орган актлары белән билгеләнгән бүтән гарантия шартлары, шулай ук мәгълүматлар.

7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китерми торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) 100 процент акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) бирә торган Татарстан Республикасында (муниципаль берәмлектә) булган хуҗалык итү ширкәте, мөлкәте Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) бирә торган Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) милкендә булган дәүләт (муниципаль) унитар

предприятиесе йөкләмәләре буенча гына бирелергә мөмкин. Принципал тулысынча яисә өлешләп хосусыйлаштырылган очракта мондый Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы белән бирелгән дип санала һәм принципалның тиешенчә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе актларында билгеләнгән срокта гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципалның гарантияне тулы күләмдә яисә кайсы да булса өлешендә үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының $115^{3}$ статьясына һәм Россия Федерациясе граждан законнарына туры килә торган йөкләмәсе барлыкка килә. Әлеге тәэмин ителеш булганчы Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантия) бирү рөхсәт ителми.

8. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясенең (муниципаль гарантиянең) үз көченә керүе календарь дата яисә гарантиядә күрсәтелгән билгеле бер вакыйга (шарт) башлану белән билгеләнә.

9. Гарантның Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) шартларын бенефициарның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртү хокукы юк.

10. Гарантка карата Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча бенефициарга бирелгән таләп хокуклары гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка тапшырыла (башка нигезләрдә күчә) алмый, моңа күрсәтелгән таләп хокукларының кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) белән тәэмин ителә торган облигацияләргә хокукның яңа хуҗага (сатып алучыга) күчүенә бәйле тапшыру керми.

11. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) гарант тарафыннан чакыртып алу гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләрдә (шул исәптән төп йөкләмәнең әлеге статьяның 6 пунктындагы 14 пунктчасында күрсәтелгән шартлары гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртелгән очракта), шулай ук принципал әлеге статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының $115^{3}$ статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән йөкләмәне үтәмәгән очракта башкарыла.

12. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча акчаларны түләү турында бенефициар таләбе (гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе), гаранттан бары тик гарантиядә билгеләнгән (гарантия очрагы барлыкка килгән) очракта гына таләп ителә ала. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе гарантка гарантиядә билгеләнгән тәртиптә, гарантиядә күрсәтелгән документларны кушымта итеп язма рәвештә тапшырылырга тиеш.

13. Бенефициар Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) һәм Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) бирү турында шартнамәдә билгеләнгән сроктан иртәрәк, шул исәптән принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен үтәү

срогы җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) барлыкка килгән очракта гарантияне үтәү турында таләп итәргә тиеш түгел.

14. Гарант бенефициарның гарантияне үтәүне таләп итүе хакында принципалга хәбәр итәргә һәм принципалга таләпнең күчермәсен тапшырырга тиеш.

15. Гарант Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) билгеләнгән срокта гарантияне үтәү хакында бенефициар таләбенең, күрсәтелгән таләпкә кушып бирелгән документларның нигезле булуын һәм таләпнең, кушып бирелгән документларның гарантия шартларына туры килү-килмәвен карарга тиеш.

16. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе һәм аңа кушып бирелгән документлар түбәндәге очракларда нигезсез һәм (яисә) гарантия шартларына туры килми дип таныла һәм гарант бенефициар таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантиядә билгеләнгән срок (гарантия гамәлдә булган срок) узганнан соң гарантка бирелсә;

2) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиядә билгеләнгән шартларны бозып тапшырылса;

3) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантия шартларына туры килмәсә;

4) бенефициар принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең принципал һәм (яисә) өченче затлар тәкъдим иткән тиешенчә үтәлешен кабул итүдән баш тартса;

5) әлеге статьяның 7 пунктында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының $115^3$ статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән очракларда;

6) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

17. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) шартларына туры килми дип танылган очракта гарант бенефициарга таләбен канәгатьләндерүдән баш тарту турында хәбәр итәргә тиеш.

18. Гарант бенефициар таләбенә каршы чыгарга хокуклы, бу каршылыкны принципал тәкъдим итәргә мөмкин. Гарант, хәтта принципал әлеге каршылыклардан баш тарткан яисә үз бурычын таныган очракта да, шушы каршылыкларга хокукын югалтмый.

19. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе һәм аңа кушып бирелгән документлар нигезле һәм Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясенә (муниципаль гарантиягә) туры килә дип танылган очракта, гарант гарантиядә билгеләнгән вакытта гарантия буенча йөкләмәне үтәргә тиеш.

20. Гарантның бенефициар каршындагы Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) каралган йөкләмәсе принципалның гарантия белән тәэмин ителгән срогы чыккан йөкләмәләре күләмендә, әмма гарантия суммасыннан артык булмаган артмаган күләмдә акча түләү белән чикләнә.

21. Гарантның Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча бенефициар каршындагы йөкләмәсе түбәндәге очракларда туктатыла:

1) гарант бенефициарга гарантиядә билгеләнгән күләмдә акча түләсә;

2) гарантиядә билгеләнгән, ул бирелгән срок (гарантиянең гамәлдә булу срогы) узса;

3) принципал яисә өченче затлар принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен үтәсә яисә принципалның күрсәтелгән йөкләмәләре башка нигезләрдә туктатылса (гарантның гарантияне үтәве турында бенефициар тарафыннан гарантка һәм (яисә) судка бирелгән таләбе булу-булмауга бәйсез рәвештә);

4) бенефициар гарантияне гарантка кире кайтару юлы белән үз хокукларыннан баш тарту һәм (яисә) бенефициар гарантны гарантия буенча йөкләмәләреннән азат итү турында язмача гариза бирү нәтиҗәсендә, принципал гарантка Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115[1] статьясында каралган гарантияне, мондый гарантия буенча бенефициар фактта булмау һәм киләчәктә дә ул барлыкка килү өчен нигезләр булмау шарты белән, кире кайтару нәтиҗәсендә;

5) тәэмин ителеше өчен гарантия бирелгән принципал йөкләмәсе билгеләнгән срокта барлыкка килмәсә;

6) төп йөкләмә туктатылса (шул исәптән гарантның гарантияне үтәве турында бенефициар таләбе гарантка һәм (яисә) судка бирелгәннән соң принципал һәм (яисә) бенефициар юкка чыгуга бәйле рәвештә) яисә ул гамәлдән чыккан алыш-биреш дип танылса;

7) гарантка карата гарантия буенча бенефициарныкы булган таләп хокуклары, төп йөкләмә буенча хокуклар һәм (яисә) бурычлар гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка (күрсәтелгән таләп хокукларының (хокук һәм бурычларның) кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү гарантия белән тәэмин ителә торган облигацияләргә хокукның яңа хуҗага (сатып алучыга) күчүенә бәйле тапшырудан (күчүдән) тыш) бенефициар тарафыннан башка затка тапшырылса яисә башка затка күчсә;

8) төп йөкләмә буенча принципалныкы булган хокуклар һәм (яисә) бурычлар (бурыч) гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка принципал тарафыннан башка затка тапшырылса яисә бүтән нигезләрдә башка затка күчсә;

9) гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр буенча гарантияне чакыртып алу нәтиҗәсендә;

10) гарантиядә билгеләнгән бүтән очракларда.

22. Гарантның гарантия буенча йөкләмәләре туктатылганнан соң бенефициарның гарантияне тотып торуы аның шушы гарантия буенча булган теге яисә бу хокукларын саклап калмый.

23. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) туктатылу турында мәгълүмат алган гарант бу хакта бенефициарга һәм принципалга хәбәр итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) чакыртып алуга яисә туктатуга китерәчәк хәлләр барлыкка килү турында мәгълүмат алган бенефициар һәм принципал бу хакта гарантка хәбәр итәргә тиеш.

24. Гарантның Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) үтәве гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын барлыкка китерсә йә бенефициарның принципалга карата таләп хокуклары гарантка күчүгә бәйле булса, Татарстан Республикасының мондый дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) үтәү өчен акчалар тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәпкә алына, ә Татарстан Республикасының мондый дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) буенча йөкләмәләрне үтәү бюджет кредиты бирү буларак чагыла.

25. Гарант тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка китермәсә йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокукларының гарантка юл куюына бәйле булмаса, Татарстан Республикасының мондый дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) үтәү өчен акча тиешле бюджет чыгымнарында исәпкә алына.

26. Гарантия буенча йөкләмәләрне тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәү йөзеннән гарант тарафыннан түләнгән акчаларны регресс тәртибендә гарантка кайтару яисә бенефициарның принципалга карата гарантка күчкән таләп хокукларын үтәү исәбеннән гарант тарафыннан алынган акчалар бюджет кредитларын кире кайтару буларак чагылдырыла.

27. Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (муниципаль гарантияләр) белән тәэмин ителә торган кредитлар һәм заемнар максатчан булырга тиеш.

28. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) белән тәэмин ителгән кредит (заем) акчаларын максатсыз файдалану факты ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) бирү турында шартнамәдә билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, принципал һәм бенефициар Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) бирү турында шартнамәдә билгеләнгән җаваплылыкка ия була.

29. Бенефициарлары билгесез затлар даирәсе булган йөкләмәләрне тәэмин итү өчен бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясенең (муниципаль гарантиянең) үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

30. Дәүләт кыйммәтле кәгазьләрен (муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне) эмиссия нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен (муниципаль гарантияләрне) бирү һәм үтәү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

31. Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен (муниципаль гарантияләрне) бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән әлеге Кодекс белән билгеләнә.»;

26) 38 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«38 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен (муниципаль гарантияләрне) бирү һәм үтәү**»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясенә бәйле йөкләмәләр Татарстан Республикасы дәүләт бурычы составына кертелә.

Муниципаль гарантиягә бәйле йөкләмәләр муниципаль бурыч составына кертелә.»;

в) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, муниципаль берәмлекнең финанс органы бирелгән гарантияләрне, алар буенча Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) артуын, принципалларның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә принципаллар йә өченче затлар тарафыннан үтәлүе нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы дәүләт бурычының (муниципаль бурычның) кимүен, принципалларның гарантияләр белән тәэмин ителгән йөкләмәләренең тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә туктатылуын, бирелгән гарантияләр буенча түләү гаранты булуны, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрендә (муниципаль гарантияләрдә) билгеләнгән башка очракларда исәпкә алып бара.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре (муниципаль гарантияләр) хуҗалык ширкәтләре, хуҗалык партнерлыклары, җитештерү кооперативлары, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләре (мөлкәтләре хуҗалык итү хокукында булган һәм шундый дәүләт унитар предприятиеләренең йөкләмәләре буенча дәүләт гарантияләре бирүче Татарстан Республикасы дәүләт милкендә санала торган дәүләт унитар предприятиеләреннән һәм мөлкәтләре хуҗалык итү хокукында булган һәм шундый муниципаль унитар предприятиеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирүче тиешле муниципаль берәмлек милкендә санала торган муниципаль унитар предприятиеләрдән тыш), коммерциячел булмаган оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, индивидуаль эшкуарлар һәм физик затлар йөкләмәләрен үтәү өчен бирелми.»;

27) 40 статьяда:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен үтәүгә хезмәт күрсәтү, шулай ук аларны урнаштыру, сатып алу, алмаштыру һәм түләп бетерү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты генераль агенты (агенты) функцияләрен кредит оешмасы яисә бүтән махсуслаштырылган финанс оешмасы тарафыннан үтәү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән төзелгән агент килешүләре нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы бурыч йөкләмәләрен урнаштыру, сатып алу, алмаштыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты генераль агенты (агенты) функцияләрен кредит оешмасы яисә бүтән махсуслаштырылган финанс оешмасы тарафыннан үтәү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән төзелгән дәүләт контракты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта «агент килешүләрендә» сүзләрен «дәүләт контрактларында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «Муниципаль бурыч йөкләмәләрен үтәүгә хезмәт күрсәтү, шулай ук аларны урнаштыру, сатып алу, алмаштыру һәм түләп бетерү буенча җирле администрация генераль агенты (агенты) функцияләрен кредит оешмасы яисә бүтән махсуслаштырылган финанс оешмасы тарафыннан үтәү җирле администрация белән төзелгән агент килешүләре нигезендә» сүзләрен «Муниципаль бурыч йөкләмәләрен урнаштыру, сатып алу, алмаштыру буенча җирле администрация генераль агенты (агенты) функцияләрен кредит оешмасы яисә бүтән махсуслаштырылган финанс оешмасы тарафыннан үтәү җирле администрация белән төзелгән муниципаль контракт нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 пунктта «агент килешүләрендә» сүзләрен «муниципаль контрактларда» сүзләренә алмаштырырга;

28) IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 40[1] статья өстәргә:

«40[1] статья. **Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләре (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр)**

1. Татарстан Республикасы исеменнән чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләре дип танылa.

2. Муниципаль берәмлек исеменнән чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр муниципаль дәүләт кыйммәтле кәгазьләре дип танылa.

3. Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләр эмитенты булып, әгәр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында мондый хокук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бирелмәгән булса, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тора.

4. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты булып муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль хисаплашуларны гамәлгә ашыру хокукы бирелгән җирле администрация тора.

5. Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) тарафыннан чыгарылырга мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт кыйммәтле кәгазьләренең (муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең) төрләре һәм аларның эмиссиясе, әйләнеш тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнә.»;

29) 41 статьяда:

а) исемдә «җыемнардан» сүзеннән соң «, салым булмаган керемнәрдән җирле бюджетларга» сүзләрен өстәргә;

б) беренче абзацта «Федераль салымнардан һәм җыемнардан җирле бюджетларга, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм салымнар, җыемнар турындагы законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле махсус салым режимнарында каралган салымнардан һәм (яисә) региональ салымнардан» сүзләрен «аерым федераль һәм (яисә) региональ салымнардан һәм җыемнардан, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм салымнар, җыемнар турындагы законнар нигезендә Татарстан Республикасы

бюджетына күчерелергә тиешле махсус салым режимнарында каралган җыемнардан, салымнардан, салым булмаган керемнәрдән» сүзләренә алмаштырырга;

30) 43 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле бюджетларга дотацияләр;»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа җиденче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр;»;

в) җиденче абзацны сигезенче абзац дип санарга;

31) 44 статьяда:

а) 1 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктта «җирле бюджетның үз керемнәреннән» сүзләрен «җирле бюджет керемнәреннән, моңа субвенцияләр һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район һәм җирлекләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә торган бюджетара трансфертлар керми,» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта «җирле бюджетның үз керемнәреннән» сүзләрен «җирле бюджет керемнәреннән, моңа субвенцияләр һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район һәм җирлекләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә торган бюджетара трансфертлар керми,» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктта:

беренче абзацта «җирле бюджетның үз керемнәреннән» сүзләрен «җирле бюджет керемнәреннән, моңа җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район һәм җирлекләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә торган субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар керми,» сүзләренә алмаштырырга;

1 һәм 4 пунктчаларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Муниципаль берәмлекләрне ике яисә күбрәк муниципаль берәмлекләрне берләштерү юлы белән үзгәртеп төзегән очракта, үзгәртеп төзелгән муниципаль берәмлек өчен чикләүләр куллану зарурлыгын бәяләү максатларында, җирле бюджетлар керемнәрендә дотацияләр һәм (яисә) салым керемнәре өлешен исәпләү өчен әлеге статьяның 2 – 4 пунктлары нигезендә берләштерелә торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына соңгы өч финанс хисабы елында кергән түбәндәгеләрнең гомуми күләме исәпкә алына:

1) физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә башка бюджетлардан дотацияләр һәм (яисә) физик затлар кеременә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре;

2) берләштерелә торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына соңгы өч финанс хисабы елында кергән керемнәр (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район һәм җирлекләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә торган субвенцияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан тыш).»;

е) 5 пунктта:

беренче – дүртенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның 2 – 4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең, шулай ук бюджетларында башка бюджетлардан дотацияләр һәм (яисә) физик затлар керемен салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре өлеше физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән (дотациянең исәпләнгән күләме өлешеннән) артмаган күләмдә соңгы өч финанс хисабы елының икесендә җирле бюджет керемнәренең, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга муниципаль район һәм җирлекләр арасында төзелгән килешүләр нигезендә бирелә торган субвенцияләрдән һәм бюджетара трансфертлардан тыш, 5 процентыннан артмаган муниципаль берәмлекләрнең исемлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча раслана.»;

ж) 8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

32) 44[1] статьяда:

а) 1 пунктта:

беренче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктта:

беренче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 3 пунктта:

беренче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «шәһәр җирлекләренең» сүзләрен һәм «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 пунктның беренче абзацында «(шәһәр округларын да кертеп)» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

е) түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә:

«7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга әлеге шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечләрен күрсәтелгән критерийларның агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законында билгеләнгән күрсәткечләре белән чагыштырганда киметү, шулай ук җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына һәрбер шәһәр, авыл җирлеге бюджетына дотация күләмен, дотацияне (дотациянең бер өлешен) физик затлар керемнәренә салымнан шәһәр җирлекләре бюджетларына, авыл җирлекләре бюджетларына түләүләрнең өстәмә нормативлары белән алмаштыруны исәпкә алып, җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законында тиешенчә план чорының беренче елына һәм план чорының икенче елына расланган дотация күләме белән чагыштырганда киметү, түбәндәге очраклардан тыш, рөхсәт ителми:

1) федераль законнарга Россия Федерациясе субъектлары һәм шәһәр җирлекләре, авыл җирлекләре арасында бюджет вәкаләтләрен һәм (яисә) керемнәрен яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү;

2) Татарстан Республикасы законнарына һәм алар нигезендә кабул ителгән муниципаль район уставына һәм авыл җирлекләре уставларына муниципаль район һәм авыл җирлеге арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм (яисә) бюджет керемнәрен яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү;

3) Татарстан Республикасы законнарына Татарстан Республикасы һәм шәһәр җирлекләре, авыл җирлекләре арасында вәкаләтләрне яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү.

8. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр һәм (яисә) әлеге дотацияләрне физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштыручы керемнәр ала торган муниципаль берәмлекләрнең җирле администрация башлыклары (башкарма-боеру органнары җитәкчеләре) белән килешүләр төзи, аларда җирлекне социаль-икътисадый үстерү һәм җирлекнең муниципаль финансларын тернәкләндерү чаралары карала.

Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр җирлекләре, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре бирелгән очракта, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән килешүләр муниципаль районның финанс органы һәм җирлекнең

җирле администрация башлыгы (башкарма-боеру органнары җитәкчеләре) тарафыннан төзелә.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән килешүләр төзү тәртибе, сроклары һәм күрсәтелгән килешүләргә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән килешүләрне төзү тәртибен һәм срокларын бозган өчен һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан шундый килешүләрдән барлыкка килгән йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм агымдагы финанс елында тиешле җирлекнең финанс хисабы елында йөкләмәләрен үтәү нәтиҗәләре буенча кулланыла.»;

33) $44^2$ статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 6 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

г) түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пунктлар өстәргә:

«7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә муниципаль районнарның (шәһәр округларының) исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие күрсәткечләрен агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законында билгеләнгән критерий күрсәткечләре белән чагыштырганда киметү, шулай ук муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә чираттагы финанс елына һәм план чорының беренче елына һәрбер муниципаль район (шәһәр округы) бюджетына дотация күләмен, әлеге статьяның 5 пункты нигезендә дотацияне (дотациянең бер өлешен) физик затлар керемнәренә салымнан муниципаль районнар (шәһәр округлары) бюджетларына түләүләрнең өстәмә нормативлары белән алмаштыруны исәпкә алып, муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законында тиешенчә план чорының беренче елына һәм план чорының икенче елына расланган дотация күләме белән чагыштырганда киметү, түбәндәге очраклардан тыш, рөхсәт ителми:

1) федераль законнарга Россия Федерациясе субъектлары, муниципаль районнар, шәһәр округлары арасында бюджет вәкаләтләрен һәм (яисә) керемнәрен яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү;

2) Татарстан Республикасы законнарына һәм алар нигезендә кабул ителгән муниципаль район уставына һәм авыл җирлекләре уставларына муниципаль район һәм авыл җирлеге арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм (яисә) бюджет керемнәрен яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү;

3) Татарстан Республикасы законнарына Татарстан Республикасы һәм муниципаль районнар (шәһәр округлары) арасында вәкаләтләрне яңадан бүлүгә китерә торган үзгәрешләр керү.

8. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан

Республикасы бюджетыннан дотацияләр һәм (яисә) әлеге дотацияләрне физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштыручы керемнәр ала торган муниципаль берәмлекләрнең җирле администрация башлыклары (башкарма-боеру органнары җитәкчеләре) белән килешүләр төзи, аларда муниципаль районны (шәһәр округын) социаль-икътисадый үстерү һәм муниципаль районның (шәһәр округының) муниципаль финансларын тернәкләндерү чаралары карала.

Күрсәтелгән килешүләр төзү тәртибе, сроклары һәм күрсәтелгән килешүләргә таләпләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. Бу килешүләрне төзү тәртибен һәм срокларын бозган өчен һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан шундый килешүләрдән барлыкка килгән йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм агымдагы финанс елында тиешле муниципаль районның (шәһәр округының) финанс хисабы елында йөкләмәләрен үтәү нәтиҗәләре буенча кулланыла.»;

34) түбәндәге эчтәлекле $44^{2.1}$ һәм $44^{2.2}$ статьялар өстәргә:

«$44^{2.1}$ статья. **Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр дигәндә, Россия Федерациясе субъектлары карамагындагы мәсьәләләр, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен үтәгәндә чыгым йөкләмәләрен һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар аңлашыла.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирүнең максатлары һәм шартлары тиешле Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

«$44^{2.2}$ статья. **Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларның нисбәтлелегән тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә җирле бюджетларга дотацияләр һәм җирле бюджетларга башка дотацияләр**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән шартларда, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләрен бүләкләү максатларында җирле бюджетларга Татарстан

Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларның нисбәтлелеген тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә дотацияләр һәм башка дотацияләр бирелергә мөмкин.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән дотацияләрне бүлү методикасы һәм аларны бирү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан аерым муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка дотацияләр бирелергә мөмкин, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән максатларга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән дотацияләрдән гыйбарәт. Күрсәтелгән дотацияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү, Татарстан Республикасы бюджетына ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлек өчен дотацияләр бирелгән очракта, федераль бюджет турында федераль закон яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый акты белән расланган бүленеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән раслана.»;

35) $44^4$ статьяда:

а) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләрне формалаштыруга, бирүгә һәм бүлүгә гомуми таләпләрне, шулай ук муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсе күләмен Татарстан Республикасы белән финанслашуның иң чик дәрәҗәсен (процентларда) ачыклау һәм билгеләү тәртибен билгели торган кагыйдәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче һәм өченче абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәрбер субсидияне бирү һәм бүлү тәртибен билгели торган норматив хокукый актлары әлеге пунктның беренче абзацында каралган кагыйдәләр нигезендә кабул ителә.

Муниципаль берәмлек бюджетына субсидия бирү шарты муниципаль берәмлек бюджетында (җирле бюджетның җыелма бюджет язмасында) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә алар үтәлеше өчен кирәкле булган күләмдә, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү планлаштырыла торган субсидия күләмен дә кертеп, бюджет ассигнованиеләре булудан, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына субсидияләр бирү турында муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча йөкләмәләре һәм әлеге килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык күздә тотылган килешү төзүдән гыйбарәт.»;

икенче абзацны дүртенче дип санарга һәм аны үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацны бишенче абзац дип санарга һәм «бүлеп бирү» сүзләрен «бирү» сүзенә, «(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды исәбеннән субсидияләрдән гайре)» сүзләрен «(финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияләрдән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль берәмлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнарының чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субсидияләр исемлеге нигезендә карала.

Татарстан Республикасы бюджетыннан күрсәтелгән исемлеккә туры килми торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү, финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган субсидияләрдән тыш, рөхсәт ителми.»;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү (конкурс нигезендә бүленә торган субсидияләрдән, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрдән һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрдән тыш) чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертмичә генә муниципаль берәмлекләр арасында субсидияләр күләмнәрен бүлүгә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

Муниципаль берәмлекләр арасында конкурс нигезендә бүленә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субсидияләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Резерв фонды акчалары исәбеннән субсидияләрне һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар булган субсидияләрне бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән раслана.

Шул ук вакытта муниципаль берәмлекләр арасында бүленмәгән субсидияләр күләмен тиешле субсидиянең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменең 5 процентыннан артмаган һәм тиешле субсидиянең план чорының икенче

елына расланган гомуми күләменең 10 процентыннан артмаган күләмдә раслау рөхсәт ителә.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка субсидияләр бирү турында килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган килешүнең үрнәк формасы нигезендә төзелә. Җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәүгә финанс ярдәме күрсәтү максатларында җирле бюджетка субсидия бирү буенча Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәсе федераль бюджеттан финанслашкан очракта, әлеге килешү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 132 статьясындагы 3 пунктының беренче абзацында каралган таләпләргә туры килергә тиеш.»;

36) $44^5$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$44^5$ статья. **Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган башка бюджетара трансфертлар**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга түбәндәге бюджетара трансфертлар бирелә:

1) җирле үзидарә органнарының федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар белән җайга салынмаган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен, шул исәптән тулы күләмдә финанслашу очрагында;

2) җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен, шул исәптән тулы күләмдә финанслашу очрагында;

3) финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды булган бюджет ассигнованиеләре бирү очрагында;

4) Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законыннан һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законыннан тыш) һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасы һәм аларны бирү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

3. Җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларның һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларның нисбәтлелеген тәэмин итү чараларына ярдәм итү өчен җирле бюджетларга дотацияләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертларның (субвенцияләрдән тыш) гомуми күләменең һәм (яисә) физик

затлар кеременә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларына алмаштырылган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменең (дотациянең исәпләнгән күләме өлешенең) 15 процентыннан артык була алмый.

4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән раслана.

5. Әлеге статьяда билгеләнгән чикләү муниципаль берәмлекләрне, шул исәптән социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренең иң яхшы күрсәткечләренә ирешү, табигый бәла-казалардан һәм башка гадәттән тыш хәлләрдән килгән зыянны бетерү өчен бүләкләү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар суммасына, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан күрсәтелгән максатларга бирелгән башка бюджетара трансфертлар булган башка бюджетара трансфертлар суммасына арттырылырга мөмкин.»;

37) $44^6$ статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

$1^1$) федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга бирелгән субвенцияләр, мондый вәкаләтләр Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган очракта;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләр бирүне күздә тотучы Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү тәртибе һәм мондый субвенцияләрнең гомуми күләмен муниципаль берәмлекләр арасында бүлү күрсәткечләре (критерийлары) булырга тиеш.»;

в) 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән методикалар Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләр булган субвенцияләрне бүлү турында нигезләмәләре өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133 статьясы нигезендә федераль законнар, һәм (яисә) Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән раслана торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү һәм Россия Федерациясе субъектлары арасында бүлү тәртипләре таләпләренә туры килергә тиеш.»;

г) 6 пунктта «мәктәпкәчә,» сүзен төшереп калдырырга;

д) $6^1$ пунктта «мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

е) 7 пунктта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, аларга өстәмәләр кертү)» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

з) 10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү һәрбер муниципаль берәмлек һәм субвенция төре буенча Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.»;

и) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бирелә. Финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр булган субвенцияләрне җирле бюджетларга бирү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән федераль бюджеттан субвенцияләр бирү тәртибенә туры килергә тиеш.»;

38) $44^8$ статьяда:

а) дүртенче һәм бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;

әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр;»;

б) җиденче абзацта «шәһәр, авыл җирлекләре җирле үзидарәсенең тиешле органнары тарафыннан Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм салымнар, җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын үтәү шарты белән» сүзләрен «шәһәр, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районнар бюджетларыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән шартларны үтәгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль районнар бюджетларыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бирелә торган бюджетара трансфертлар, шул исәптән муниципаль районнар бюджетларына шәһәр, авыл җирлекләренә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган субвенцияләр шәһәр, авыл җирлекләренең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга әлеге Кодексның 44 статьясында каралган бюджетара трансфертлары бирүнең төп шартларын үтәү шарты белән бирелә.

Җирле бюджетлардан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешле субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар булган бюджетара трансфертларны бирү

максатлары, тәртибе һәм шартлары муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы законнары һәм (яисә) башка норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлары белән билгеләнә.»;

39) $44^9$ статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләр шушы муниципаль район составына керүче җирлекләргә муниципаль район вәкиллекле органының Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс таләпләре нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актлары нигезендә бирелә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләрнең гомуми күләме ел саен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль район бюджеты проектын төзегәндә җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә әлеге муниципаль район составына керүче җирлекләрнең бюджетларына бирелә торган һәм җирлекләрнең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериена җирлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем алу мөмкинлекләрен бәяләүдәге аерманы исәпкә алып ирешү зарурлыгыннан чыгып санала торган дотацияләрнең суммар күләме буларак билгеләнә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләрне муниципаль берәмлекләр арасында бүлү әлеге Кодекска 12 нче кушымтада билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр муниципаль район бюджеты проекты чираттагы финанс елына һәм план чорына расланса, план чорына муниципаль район бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүленмәгән күләмен күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының беренче елына расланган гомуми күләменнән 20 проценттан артмаган һәм күрсәтелгән дотацияләрнең план чорының икенче елына расланган гомуми күләменнән 20 проценттан артмаган күләмдә раслау рөхсәт ителә.»;

в) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирлекләрнең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен ачыклаганда хисап чоры өчен факттагы керемнәр һәм чыгымнар күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым җирлекләрнең фаразлана торган керемнәрен һәм чыгымнарын куллану рөхсәт ителми.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Әлеге статьяның 4 пунктында каралган дотацияләр бирелгән очракта, муниципаль районның финанс органы муниципаль район бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы муниципаль берәмлекләрнең җирле администрация башлыклары (башкарма-боеру органнары җитәкчеләре) белән килешүләр төзергә хокуклы, җирлекне социаль-икътисадый үстерү һәм җирлекнең муниципаль финансларын тернәкләндерү чаралары карала.

Килешүләрне төзү тәртибе, сроклары һәм әлеге пунктта күрсәтелгән килешүләргә таләпләр муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе (башкарма-боеру органы) тарафыннан билгеләнә.»;

40) $44^{10}$ статьяда:

а) 2 пунктта:

беренче абзацта «җирлекләргә финанс ярдәменең региональ фонды бюджет ассигнованиеләрендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре күләмен формалаштырганда» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «вәкиллекле органнарына» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга, «җирлекләр» сүзен «шәһәр, авыл җирлекләре» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «муниципаль районнарга (шәһәр округларына) финанс ярдәменең региональ фонды бюджет ассигнованиеләрендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре күләмен формалаштырганда» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «вәкиллекле органнарына» сүзләрен «җирле

б) 3 пунктның бишенче абзацында «бюджетара» сүзен төшереп калдырырга, «кимрәк» сүзен «азрак» сүзенә алмаштырырга;

в) 4 пунктның беренче абзацында «бюджетара» сүзен төшереп калдырырга;

г) 5 пунктта:

беренче абзацта «бюджетара субсидияләр» сүзен «субсидияләр» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «бюджетара субсидияләр күчерү» сүзләрен «субсидияләр күчерү» сүзләрен алмаштырырга, «субсидияләр суммасы» сүзләрен «субсидияләр күләмен» сүзләренә алмаштырырга, «каралган салымнардан» сүзләреннән соң «, җирле салымнардан һәм җыемнардан» сүзләрен өстәргә;

41) $44^{11}$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$44^{11}$ статья. **Җирле бюджетлардан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Кодекс таләпләре нигезендә кабул ителә торган муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актларында каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында муниципаль берәмлек бюджетыннан башка муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирелергә мөмкин.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатлары һәм шартлары җирле администрацияләр арасында бюджетыннан субсидия бирелә торган

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнгән тәртиптә төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.»;

42) 44[13] статьяда «очракларда һәм тәртиптә» сүзләреннән соң «төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга» сүзләрен өстәргә;

43) 47 статьяның 1 пунктында:

а) беренче абзацта «башкарма органнары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

б) «башкарма-боеру органының» сүзләрен «җирле администрациянең (башкарма-боеру органының)» сүзләренә алмаштырырга;

44) 47[1] статьяда:

а) 1 пунктта «(вазыйфаи затлары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның алтынчы абзацында «бюджет акчаларының баш администраторлары» сүзләрен «бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (алга таба – бюджет акчаларының баш администраторлары, бюджет чараларының баш администраторлары)» сүзләренә алмаштырырга, «эчке финанс контроле һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктта «(вазыйфаи затлары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 пунктта:

беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

икенче абзацта «тиешенчә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, җирле администрация органы (вазыйфаи затлары) булып торучы муниципаль финанс контроле органы» сүзләрен «Федераль казначылык» сүзләренә алмаштырырга, «эчке финанс контролен һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

45) 49 статьяда:

а) җиденче абзацта «бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бюджет керемнәренең баш администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары» сүзләрен «бюджет акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) унынчы абзацка «, шулай ук Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләре реестрын тапшыру тәртибен раслый» сүзләрен өстәргә;

в) утызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары нигезендә принципалның финанс хәлен тикшерүне (анализлауны), принципалның Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе бирелгәндә гарантия буенча йөкләмәләрне тулы күләмдә яисә кайсы да булса өлешендә үтәгән гарант тарафыннан принципалга карата регресс таләбе бирүгә бәйле рәвештә киләчәктә барлыкка килергә мөмкин йөкләмәләрен

үтәүгә бирелә торган тәэмин ителешнең җитәрлек, ышанычлы булуын һәм ликвидлылыгын тикшерүне, шулай ук принципалның финанс хәленә мониторинг ясауны, Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе бирелгәннән соң тәкъдим ителгән тәэмин ителешнең җитәрлек, ышанычлы булуын һәм ликвидлылыгын контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;»;

46) 50 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

47) 50 статьяның ундүртенче абзацында «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрдән, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторларыннан, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре баш администраторларыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга;

48) 53 статьяның 1 пунктында «финанс органнарыннан,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының идарә органнарыннан,» сүзләрен өстәргә;

49) 55 статьяның 4 пунктында икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Күрсәтелгән субсидияләрне бирү һәм бүлү тәртипләре тиешле Татарстан Республикасы дәүләт программасында билгеләнә.»;

50) 61 статьяның 4 пунктындагы сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы эчке дәүләт бурычының иң югары чиге һәм (яисә) Татарстан Республикасы тышкы дәүләт бурычының иң югары чиге;»;

51) 77 статьяның 3 пунктындагы сигезенче абзацта татарча текст үзгәрми;

52) $77^1$ статьяның 2 пунктындагы беренче абзацта «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга;

53) 78 статьяның 5 пунктында:

а) беренче һәм икенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче һәм дүртенче абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет йөкләмәләрен һәм акчалата йөкләмәләрне исәпкә куйганда, акчалата йөкләмәләрне түләүне

санкциялəгəндə, əлеге статьяның 1 пунктындагы үзе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тикшереп тора:

бюджет йөкләмәләрен тиешле бюджет йөкләмәләре лимитларыннан яисә бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләреннән арттырмауны, шулай ук бюджет йөкләмәсе турында мәгълүматның бюджетларның чыгымнар классификациясе кодына туры килү-килмәвен;»;

в) түбәндәге эчтәлекле бишенче – тугызынчы абзацлар өстәргә:

«акчалата йөкләмә турындагы мәгълүматның исәпкә куелган тиешле бюджет йөкләмәсе турындагы мәгълүматка туры килү-килмәвен;

акчалата йөкләмәгә түләү өчен булган түләү документында күрсәтелгән мәгълүматның акчалата йөкләмә турындагы мәгълүматка туры килү-килмәвен;

акчалата йөкләмә барлыкка килүне раслый торган документларның булуын.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән һәм әлеге статьяның 1 пунктында каралган тәртиптә, әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматка өстәп, контрольгә алынырга тиешле бүтән мәгълүмат билгеләнергә мөмкин.

Бюджет йөкләмәсе дәүләт контракты нигезендә барлыкка килгән очракта, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында каралган контрактлар реестрында дәүләт контракты турындагы белешмәләрнең һәм дәүләт контракты нигезендә барлыкка килгән бюджет йөкләмәсенең исәпкә куелуы турындагы белешмәләрнең дәүләт контракты шартларына туры килү-килмәве өстәмә рәвештә контрольдә тотыла.»;

г) өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә унынчы һәм унберенче абзацлар дип санарга;

54) $80^2$ статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «сатып алуларның планнарын» сүзләрен «сатып алуларның план-графикларын» сүзләренә алмаштырырга;

55) $97^1$ статьяда:

а) 3 пунктта:

дүртенче абзацта «керемнәрнең ярдәмче төрләре, чыгымнар төрләре төркемчәләре һәм (яисә) элементлары, бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары төрләре кодлары буенча бюджетлар счетлары гамәлләре» сүзләрен «дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча бюджет акчалары белән гамәлләр» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «бюджет үтәлешенең һәм бюджет хисаплылыгының анализы, шулай ук финанс хисабы елында дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәү турында һәм бюджет акчаларын баш бүлүчеләр (бүлүчеләр, алучылар) тарафыннан бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр» сүзләрен «, бюджет үтәлеше турында хисапта бирелгән мәгълүматка өстәп, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының норматив хокукый

актларында билгеләнгән мәгълүматны ачу таләпләренә туры китереп, бюджет үтәлеше турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «һәм стандартларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары буенча физик затларга хезмәт өчен түләү һәм башка түләүләрне исәпләү буенча, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына алар белән бәйле мәҗбүри түләүләрне исәпләү һәм аларны күчерү буенча, бюджет хисабын, бюджет һәм автоном учреждениеләрнең берләштерелгән хисабын, бюджет исәбе белешмәләренә нигезләнеп төзелә торган башка мәҗбүри хисапны төзү һәм тапшыруны кертеп, бюджет исәбен алып бару буенча, мондый хисапны тиешле дәүләт органнарына бирүне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары (аларның территориаль органнары, ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләре) вәкаләтләре, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләргә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылырга мөмкин.»;

г) 5 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) акчаларын баш бүлүчеләр, Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) керемнәренең баш администраторлары, Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты (җирле бюджет) акчаларының баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга, «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

д) 6 пунктта «җыелма» сүзен төшереп калдырырга;

56) $97^2$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Әлеге статья нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бюджет хисабын тапшыру ул билгеләгән срокларда гамәлгә ашырыла.»;

57) $97^3$ статьяның 2 пунктындагы икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Җирле бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы Татарстан Республикасы Хисап палатасы белән аңа тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзегән очракта һәм «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла ала.»;

58) $97^4$ статьяның 2 пунктындагы 5 пунктчасында «аңлатма язуы» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисабына анализны үз эченә алган аңлатма язуы һәм дәүләт

йөкләмәсен үтәү һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдаланунын башка нәтиҗәләре турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

59) 98 статьяда:

а) 1 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе бюджет законнарын һәм бюджет мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актларны» сүзләрен «бюджет мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезләмәләрен, физик затларга Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларыннан гавами норматив йөкләмәләрне һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрне, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары, бюджеттан акча бирү турында шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү өчен нигез булган хокукый актларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта «Бюджет мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктта «Бюджетка караган хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә», «(вазыйфаи затлары)», «, муниципаль берәмлекләрнең финанс органнарының» сүзләрен төшереп калдырырга;

60) 100 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

61) 101 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Эчке дәүләт финанс контроле Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән расланган федераль стандартлар нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроленең федераль стандартларында каралган очракларда, эчке дәүләт финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган ведомство хокукый актларын (стандартларын) чыгара ала.»;

62) 1 нче кушымтада:

а) 1 пунктның бишенче абзацында «финанс ярдәменең тиешле фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Физик затлар кеременә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативы өтердән соңгы дүртенче санга кадәрле төгәллек белән исәпләнә.»;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта «финанс ярдәменең тиешле фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «бюджетына финанс ярдәменең тиешле фондыннан» сүзләрен «бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «финанс ярдәменең тиешле фондыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән» сүзләренә алмаштырырга;

63) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
2 нче кушымта

**Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр булдыру һәм бүлү тәртибе**

1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме, күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең, авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критериеларына ирешү зарурлыгыннан чыгып, ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең гомуми күләме әлеге Кодексның $44^{10}$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларыннан күчерелә торган субсидияләр күләменнән ким булырга тиеш түгел.

3. Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие, авыл җирлекләре арасында бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткечен Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр яисә муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр бирү өчен каралган муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр өлешен бирү нәтиҗәсендә арттыру зарурлыгыннан чыгып, ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

Авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_{сп} = \left( \frac{УНП^{i}_{сп}}{Ч^{i}_{сп}} \right)_{мин} \times Коэф_{ипц},$$

монда:

$К_{сп}$ – авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча авыл җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие;

$УНП^{i}_{сп}$ – тигезләүгә кадәр i-авыл җирлегенең шартлы салым потенциалы, ул әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла;

$Ч^{i}_{сп}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

$\left(\frac{УНП^{i}_{сп}}{Ч^{i}_{сп}}\right)_{мин}$ – тигезләүгә кадәр бер кешегә исәпләгәндә шартлы салым потенциалы күләменең авыл җирлекләре арасында минималь күрсәткече;

$Коэф_{ипц}$ – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә куллану бәяләре индексы.

4. Шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләрнең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие, шәһәр җирлекләре арасында бер кешегә исәпләнгән шартлы салым потенциалы күләменең минималь күрсәткечен Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр яисә муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр җирлекләре бюджетларына дотацияләр бирү өчен каралган муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр өлешен бирү нәтиҗәсендә арттыру зарурлыгыннан чыгып, ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

Шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие буларак билгеләнә торган дәрәҗә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_{гп} = \left(\frac{УНП^{i}_{гп}}{Ч^{i}_{гп}}\right)_{мин} \times Коэф_{ипц},$$

монда:

$К_{гп}$ – шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча шәһәр җирлекләренең финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерие;

$УНП^{i}_{гп}$ – тигезләүгә кадәр i-шәһәр җирлегенең шартлы салым потенциалы, ул әлеге Кодексның 7 нче кушымтасында билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла;

$Ч^{i}_{ГП}$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

$\left(\frac{УНП^{i}_{ГП}}{Ч^{i}_{ГП}}\right)_{мин}$ – тигезләүгә кадәр бер кешегә исәпләгәндә шартлы салым потенциалы күләменең шәһәр җирлекләре арасында минималь күрсәткече;

$Коэф_{ипц}$ – Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә куллану бәяләре индексы.

5. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне һәм авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне үз эченә ала.

Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне шәһәр җирлекләре бюджетлары арасында бүлү әлеге Тәртипнең 6 – 15 пунктлары нигезендә башкарыла, шул ук вакытта әлеге Кодексның $44^{1}$ статьясындагы 3 пунктында каралган дотацияләр өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрне авыл җирлекләре бюджетлары арасында бүлү әлеге Тәртипнең 16 – 25 пунктлары нигезендә башкарыла, шул ук вакытта әлеге Кодексның $44^{1}$ статьясындагы 3 пунктында каралган дотацияләр өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

6. J-шәһәр җирлеге өчен, халык саныннан чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Дч^{j}_{ГП} = V_{ГПч} \times \frac{Ч^{j}_{ГП}}{SUM^{n}_{j=1} Ч^{j}_{ГП}},$$

монда:

$Дч^{j}_{ГП}$ – j-шәһәр җирлеге өчен, халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме;

$V_{ГПч}$ – халык саныннан чыгып, шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме;

$Ч^{j}_{ГП}$ – j-шәһәр җирлегенең халык саны;

n – Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алу хокукына ия шәһәр җирлекләре саны.

7. Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр күләме, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше – исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү

ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$$D^i = D_1^i + D_2^i,$$

монда:

$D^i$ – i-шәһәр җирлегенә Татарстан Республикасы бюджетыннан шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, дотацияләрнең гомуми күләме;

$D_1^i$ – i-шәһәр җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D_2^i$ – i-шәһәр җирлегенә «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

8. Шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып төрле ысуллар белән бүленә торган дотацияләрнең өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

9. Дотацияләр өлешен исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_1^i = d_{\text{пп}} \times V_{\text{ГПрбо}} \times \frac{H^i}{H},$$

монда:

$D_1^i$ – i-шәһәр җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{\text{пп}}$ – шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган дотацияләр өлеше;

$V_{\text{ГПрбо}}$ – шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, дотацияләр күләме;

$H^i$ – шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме;

$H$ – шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә барлык шәһәр җирлекләре ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме.

10. Шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлегенең ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Н^{i} = ИБР^{i} \times Ч^{i} \times \left(К - БО^{i}_{расч}\right) \times \frac{SUM^{n}_{i=1} УНП^{i}}{SUM^{n}_{i=1} Ч^{i}},$$

монда:

$Н^{i}$ – шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-шәһәр җирлеге ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

К – шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^{i}_{расч}$ – i-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^{i}$ – i-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре саны.

11. Шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә муниципаль берәмлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләгәндәге аерманы исәпкә алып билгеләнә.

12. Шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә ирешү өчен җитми торган акчалар күләме шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннан кимрәк булган шәһәр җирлекләре буенча гына исәпләп чыгарыла:

$$\left(БО^{i}_{расч} < К\right).$$

13. Шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң, шәһәр җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешенең ирешелгән дәрәҗәсе билгеләнә, ул шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$БО^{i}_{1} = БО^{i}_{расч} + \frac{Н^{i} \times SUM^{n}_{i=1} Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{n}_{i=1} УНП^{i}},$$

монда:

$БО_1^i$ – шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң і-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО_{расч}^i$ – шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүленгәнгә кадәр і-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$Н^i$ – шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган і-шәһәр җирлегенә шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлеше күләме;

$ИБР^i$ – і-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – і-шәһәр җирлегенең халык саны;

$УНП^i$ – і-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре саны.

14. Дотацияләр өлешен «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_2^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(БО - БО_1^i\right) \times \frac{SUM_{i=1}^n УНП^i}{SUM_{i=1}^n Ч^i},$$

монда:

$D_2^i$ – і-шәһәр җирлегенә «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – исәпләнгән бюджет тәэмин ителешенең тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗәсе;

$БО_1^i$ – шәһәр җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң і-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – і-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – і-шәһәр җирлегенең халык саны;

$УНП^i$ – і-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

n – Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре саны.

15. I-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе, бюджет хезмәтләрен күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның барлык шәһәр җирлекләре буенча бер кешегә карата исәпләп чыгарылган шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы чагыштырмасы буларак билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$БО^i_{расч} = \frac{УНП^i \times SUM^n_{i=1} Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM^n_{i=1} УНП^i},$$

монда:

$БО^i_{расч}$ – i-шәһәр җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^i$ – i-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП^i$ – i-шәһәр җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^i$ – i-шәһәр җирлегенең халык саны;

n – Татарстан Республикасында шәһәр җирлекләре саны.

16. J-авыл җирлеге өчен, халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Дч^j_{СП} = V_{СПч} \times \frac{Ч^j_{СП}}{SUM^s_{j=1} Ч^j_{СП}},$$

монда:

$Дч^j_{СП}$ – j-авыл җирлеге өчен, халык саныннан чыгып, Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме;

$V_{СПч}$ – халык саныннан чыгып, авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләме;

$Ч^j_{сп}$ – j-авыл җирлегенең халык саны;

s – Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр алу хокукына ия авыл җирлекләре саны.

17. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр күләме, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, катнаш ысул белән билгеләнә. Дотацияләрнең беренче өлеше – исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып; дотацияләрнең икенче өлеше «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулын кулланып бүленә:

$D^i = D_1^i + D_2^i,$

монда:

$D^i$ – i-авыл җирлегенә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып, дотацияләрнең гомуми күләме;

$D_1^i$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$D_2^i$ – i-авыл җирлегенә «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме.

18. Авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып төрле ысуллар белән бүленә торган дотацияләрнең өлешләре арасындагы нисбәт ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә билгеләнә.

19. Дотацияләр өлешен исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D_1^i = d_{ПП} \times V_{СПрбо} \times \frac{H^i}{H},$$

монда:

$D_1^i$ – i-авыл җирлегенә пропорциональ тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

$d_{пп}$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып тигезләүгә пропорциональ тигезләү ысулын кулланып бүленә торган дотацияләр өлеше;

$V_{СПрбо}$ – авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып тигезләүгә дотацияләр күләме;

$H^i$ – авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлеге ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме;

H – авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә барлык авыл җирлекләре ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме.

20. Авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә i-авыл җирлегенең ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$H^i = ИБР^i \times Ч^i \times \left(К - БО^i_{расч}\right) \times \frac{SUM^s_{i=1} УНП^i}{SUM^s_{i=1} Ч^i},$$

монда:

$Н^i$ – авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә і-авыл җирлеге ирешүе өчен кирәкле акчалар күләме;

$ИБР^i$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^i$ – і-авыл җирлегенең халык саны;

К – авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие;

$БО^i_{расч}$ – і-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$УНП^i$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасында авыл җирлекләре саны.

21. Авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзегәндә муниципаль берәмлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләгәндәге аерманы исәпкә алып билгеләнә.

22. Авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсенә і-авыл җирлегенең ирешүе өчен җитми торган акчалар күләме исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериеннан кимрәк булган авыл җирлекләре буенча гына исәпләп чыгарыла:

$$\left(БО^i_{расч} < K\right).$$

23. Авыл җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң авыл җирлекләренең исәпләнгән бюджет тәэмин ителешенең ирешелгән дәрәҗәсе билгеләнә, ул авыл җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең икенче өлешен бүлгәндә кулланыла һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$БО^i_1 = БО^i_{расч} + \frac{Н^i \times SUM^s_{i=1} Ч^i}{ИБР^i \times Ч^i \times SUM^s_{i=1} УНП^i},$$

монда:

$БО^i_1$ – авыл җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен

тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң і-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$БО^{i}_{расч}$ – авыл җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып авыл җирлекләре арасында бүленә торган шәһәр җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүленгәнгә кадәр і-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$Н^{i}$ – авыл җирлекләре арасында, исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган і-авыл җирлегенә авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлеше күләме;

$ИБР^{i}$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – і-авыл җирлегенең халык саны;

$УНП^{i}$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасында авыл җирлекләре саны.

24. «Гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулын файдаланып дотацияләр өлешен бүлү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$D^{i}_{2} = ИБР^{i} \times Ч^{i} \times \left(БО - БО^{i}_{1}\right) \times \frac{SUM^{s}_{i=1} УНП^{i}}{SUM^{s}_{i=1} Ч^{i}},$$

монда:

$D^{i}_{2}$ – і-авыл җирлегенә бүленеше «гарантияләнгән минимум»га кадәр тигезләү ысулы белән бүленә торган дотацияләр өлеше күләме;

БО – исәпләнгән бюджет тәэмин ителешенең тигезләү башкарыла торган минималь дәрәҗәсе;

$БО^{i}_{1}$ – авыл җирлекләре арасында исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән чыгып бүленә торган авыл җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең беренче өлешен бүлгәннән соң і-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^{i}$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$Ч^{i}$ – і-авыл җирлегенең халык саны;

$УНП^{i}$ – і-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

s – Татарстан Республикасында авыл җирлекләре саны.

25. І-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе, бюджет хезмәтләрен күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган объектив факторларны һәм шартларны исәпкә алып, аның барлык авыл җирлекләре буенча бер кешегә карата исәпләп чыгарылган шундый ук күрсәткечкә шартлы салым потенциалы

чагыштырмасы буларак билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$БО^{i}_{расч} = \frac{УНП^{i} \times SUM^{s}_{i=1}Ч^{i}}{ИБР^{i} \times Ч^{i} \times SUM^{s}_{i=1}УНП^{i}},$$

монда:

$БО^{i}_{расч}$ – i-авыл җирлегенең исәпләнгән бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе;

$ИБР^{i}$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 6 нчы кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган бюджет чыгымнары индексы;

$УНП^{i}$ – i-авыл җирлегенең әлеге Кодекска 7 нче кушымтада билгеләнгән Тәртип нигезендә исәпләп чыгарыла торган шартлы салым потенциалы;

$Ч^{i}$ – i-авыл җирлегенең халык саны;

s – Татарстан Республикасында авыл җирлекләре саны.»;

64) 5 нче кушымтаның 8 пунктында «($БО^{i}$<К)» сүзләрен «$\left(БО^{i}_{расч} < K\right)$» сүзләренә алмаштырырга;

65) $9^2$ нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
$9^2$ нче кушымта

**Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне исәпләү методикасы**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына субвенция муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итү өчен билгеләнә.

2. Әлеге Методика муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем

алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне елына бер укучыга исәпләгәндә тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативын куллануга нигезләнә.

3. Субвенцияне исәпләп чыгарганда планлаштырыла торган елга кадәрге елның 1 сентябренә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның уку-укыту программаларының төрләре (профильләре), гомуми белем бирү дәрәҗәләре, уку формалары буенча факттагы саны кулланыла.

4. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә субвенциянең гомуми күләме (S) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S = \underset{i=1}{\overset{45}{SUM}} S_i \quad ,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль берәмлегенең муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә субвенция күләме.

5. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен субвенцияне ($S_i$) исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_i = S_N + S_{SN},$$

монда:

$S_N$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карап исәпләнә торган субвенция күләме;

$S_{SN}$ – i-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт

гарантияләрен тәэмин итүгә сыйныфларның норматив тулылыгыннан арткан сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карап исәпләнә торган субвенция күләме.

6. I-муниципаль берәмлегенә муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә субвенция күләмен сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфлар буенча белем алучыларның санына карап исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_N = \mathrm{SUM}_{n=1}^{3}\left(R_{jcp} \times H_{ijcp}^{fn}\right)_n + \mathrm{SUM}_{n=1}^{3}\left(R_j^{g.p.d.} \times H_{ij}^{g.p.d.}\right)_n + \mathrm{SUM}_{n=1}^{3}\left(R_j^{d.o.} \times H_{ij}^{f.d.o.}\right)_n +$$
$$+ \mathrm{SUM}_{n=1}^{3}\left(R_j^{e.} \times H_{ij}^{e.}\right)_n + \mathrm{SUM}_{n=1}^{3}\left(R_j^{i.} \times H_{ij}^{i.}\right)_n ,$$

монда:

$R_{jcp}$, $R_j^{i.}$, $R_j^{g.p.d.}$, $R_j^{e.}$, $R_j^{d.o.}$ – индивидуаль уку рәвешендә белем алуны, озайтылган көн төркемнәрендә белем алуны, экстернат рәвешендә белем алуны исәпкә алып, төп гомуми белем бирү программаларын (башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программаларын) гамәлгә ашыруга, өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында бер белем алучыга исәпләнгән финанс чыгымнары нормативлары;

$H_{ijcp}^{fn}$, $H_{ij}^{i.}$, $H_{ij}^{g.p.d.}$, $H_{ij}^{e.}$, $H_{ij}^{f.d.o.}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендәге j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында, индивидуаль уку, озайтылган көн төркемнәрендә уку, экстернат рәвешендә уку рәвешендә белем алган белем алучылар санын исәпкә алып, төп гомуми белем бирү программалары (башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программалары) буенча, өстәмә белем бирү программалары буенча сыйныфларның норматив тулылыгы чикләрендә сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны;

n – гомуми белем баскычы;

c – сыйныф төре;

p – укыту профиле.

7. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә i-муниципаль берәмлеге өчен субвенция күләмен сыйныфларның норматив тулылыгыннан артып киткән сыйныфлар санына карата исәпләп чыгару түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_{SN} = \underset{n=1}{\overset{3}{SUM}}\left(k \times \left(R_{jcp} \times \left(H^{f}_{ijcp} - H^{nm}_{ijcp}\right)\right)\right)_{n},$$

монда:

$R_{jcp}$ – j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасында бер укучыга исәпләгәндә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнары нормативлары;

$H^{f}_{ijcp}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендә j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасының төп гомуми белем бирү программалары буенча сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны;

$H^{nm}_{ijcp}$ – i-муниципаль берәмлеге территориясендә j-муниципаль гомуми белем бирү оешмасының төп гомуми белем бирү программалары буенча сыйныфларның норматив тулылыгы нигезендә сыйныфларда белем алучылар саны;

k – финанс белән тәэмин ителеш коэффициенты;

n – гомуми белем баскычы;

c – сыйныф төре;

p – укыту профиле.

8. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

9. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын исәпләп чыгару буенча методик тәкъдимнәр, финанс белән тәэмин ителеш коэффициенты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

10. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләрне җирле бюджетларга бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.»;

66) $9^{2.1}$ нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Бюджет кодексына
$9^{2.1}$ нче кушымта

**Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне исәпләү методикасы**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенция мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында (алга таба – муниципаль мәгариф оешмалары) һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү өчен билгеләнгән.

2. Әлеге Методика мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнарының бер тәрбияләнүчегә исәпләнгән нормативын куллануга нигезләнә.

3. Субвенцияне исәпләгәндә тәрбияләнүчеләрнең, планлаштырыла торган елга кадәрге елның 1 сентябренә муниципаль мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең категорияләре, яшь составы буенча төркемнәрнең иң чик тулылыгыннан артмаган фактагы саны кулланыла.

4. Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә субвенцияләрнең гомуми күләме ($S$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \sum_{i=1}^{45} S_i ,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль берәмлегенең муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә субвенция күләме.

5. I-муниципаль берәмлеге өчен субвенция күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Si = \sum_{z=1}^{2} \left(R^{ob}_{tzy} \times H^{ob}_{itzy}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R^{ozd}_{tzy} \times H^{ozd}_{itzy}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R^{komp}_{qtzy} \times H^{komp}_{iqtzy}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R^{mds}_{tzy} \times G^{mds}_{itzy}\right) + \sum_{z=1}^{2} \left(R^{komb}_{qtzy} \times H^{komb}_{iqtzy}\right),$$

монда:

$R^{ob}_{txy}$, $R^{ozd}_{txy}$, $R^{komp}_{qtxy}$, $R^{mds}_{txy}$, $R^{komb}_{qtxy}$ – мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга финанс чыгымнарының тиешенчә гомуми үсеш юнәлешендәге, сәламәтләндерү юнәлешендәге, компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдәге, аз комплектлы балалар бакчалары төркемнәрендәге, катнаш юнәлештәге төркемнәрдәге бер тәрбияләнүчегә исәпләнгән нормативы;

$H^{ob}_{itxy}$, $H^{ozd}_{itxy}$, $H^{komp}_{iqtxy}$, $H^{komb}_{iqtxy}$ – мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программалары буенча тиешенчә гомуми үсеш юнәлешендәге, сәламәтләндерү юнәлешендәге, компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдә, катнаш юнәлештәге төркемнәрдә белем алучыларның i-муниципаль берәмлегендә әлеге Методиканың 3 пункты нигезендә билгеләнә торган саны;

$G^{mds}_{itxy}$ – i-муниципаль берәмлегенең аз комплектлы мәктәпкәчә белем бирү оешмасы төркемнәре саны;

t – муниципаль мәгариф оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге);

x – муниципаль мәгариф оешмасында төркемнең эш көннәре саны;

y – муниципаль мәгариф оешмасы төркемендә балаларның булу дәвамлылыгы;

z – муниципаль мәгариф оешмасы төркемендә тәрбияләнүчеләрнең яшь буенча составы;

ob – гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәр;

ozd – сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәр;

komp – компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәр;

mds – аз комплектлы балалар бакчалары;

komb – катнаш юнәлештәге төркемнәр;

q – муниципаль мәгариф оешмасының компенсацияләү һәм катнаш юнәлешләрдәге төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр категориясе (авырулар буенча).

6. Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

7. Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

8. Муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләрне бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана.»;

67) $9^3$ нче кушымтада:

а) 1 пунктта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга, «(алга таба – дәүләт вәкаләтләре)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_{svod} = \sum_{i=1}^{n} C_{i\ присяжн.},$$

монда:

$C_{svod}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрнең гомуми күләме;

$C_{i\ присяжн.}$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлегенә субвенцияләр күләме;

n – дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлекләр саны.»;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чi – i-муниципаль берәмлегендә суд рәисләре заявкалары буенча присяжный утырышчыларга кандидатлар исемлегенә кертелергә тиешле йә i-муниципаль берәмлегендә присяжный утырышчылар булу хокукын югалткан (исемлекләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта) гражданнар саны;»;

утызынчы абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

утыз дүртенче абзацта «(үзгәртү)» сүзен «(үзгәртү, өстәү)» сүзләренә алмаштырырга;

утыз җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Ci$ присяжн $= C\ svod\ \ /\ \ Csvod\ уточн. \times Ci\ уточн.$»;

утыз тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

кырыгынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$Csvod\ уточн.$ – барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округлары буенча субвенцияләргә төгәлләштерелгән ихтыяҗ.»;

68) 10 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

69) 12 нче кушымтаның 9 пунктында «(БОj<K)» сүзләрен «$(\text{БО}^{j}_{\text{расч}} < K)$» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (II өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Территорияләрендә халыкара спорт ярышлары Россия Федерациясе Президенты һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте кабул иткән карар нигезендә үткәрелгән, бюджетларында Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләргә һәм (яисә), күчерелгән акчаларның өстәмә нормативлары белән алмаштырылып, бюджет тәэмин ителешен (дотациянең исәпләнгән күләме өлешен) тигезләүгә дотациянең исәпләнгән күләменнән артып китмәгән күләмдә күчерелгән акчаларның өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренә туры килгән өлеш хисап елында җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 5 процентыннан артып китмәгән, 2017 елның 1 гыйнварына муниципаль бурыч күләме, кире кайтарылмый торган кергән акчаларның һәм (яисә) күчерелгән акчаларның өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән кергән акчаларның расланган күләмен исәпкә алмыйча, җирле бюджет керемнәре күләменең 100 проценттан күбрәк тәшкил иткән муниципаль берәмлекләргә кагылышлы муниципаль бурыч күләме 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 5 пунктында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән чикләүдән, агымдагы елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы законы нигезендә реструктурлаштырылган бюджет кредитлары буенча муниципаль бурыч күләме чикләрендә артып китәргә мөмкин. 2025 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль бурычның югары чиге әлеге өлештә күрсәтелгән шартларны үтәп билгеләнә.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 8 пункты, 12 пунктының уникенче – ундүртенче, уналтынчы, унҗиденче, егерме беренче һәм егерме икенче абзацлары, 13 пункты, 17 пунктының өченче – алтынчы һәм унынчы абзацлары, 19 пунктының икенче – унынчы абзацлары, 21 пунктының өченче – сигезенче абзацлары, 25 һәм 26 пунктлары һәм 2 статьясы 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 61 пункты 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4. Әлеге Законның 1 статьясындагы 7 пунктының «в» һәм «д» пунктчалары, 14 пунктының бишенче һәм алтынчы абзацлары, 22 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының (әлеге Закон редакциясендә) 4 статьясындагы уналтынчы һәм унҗиденче абзацлары, 5 статьясындагы 2 пункты, 15 һәм 16 статьялары, 25 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 7 пунктлары, 26 статьясы, 27 статьясындагы $3^1$ һәм $3^2$ пунктлары, 29 статьясындагы 1, 2, 4 – 7 пунктлары, $29^1$ статьясы, $29^3$ статьясындагы 1 һәм 2 пунктлары, 31 статьясындагы 1 – 6 пунктлары, $31^{1.1}$, $31^{1.3}$, 32, 41, 43, 44, $44^1$, $44^2$, $44^{2.1}$, $44^{2.2}$, $44^4$, $44^5$, $44^6$, $44^8$, $44^9$, $44^{10}$, $44^{11}$, $44^{13}$ һәм 47 статьялары, 49 статьясындагы унынчы абзацы, 55 статьясының 4 пункты, 61 статьясындагы 4 пунктының сигезенче абзацы, 1, 2, $9^2$, $9^{2.1}$, $9^3$ һәм 12 нче кушымталары нигезләмәләре, 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

6. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының (әлеге Закон редакциясендә) 29 статьясындагы 11, 14 – 16 һәм 19 пунктларының, 31 статьясындагы 7 пунктының, $31^1$ статьясындагы 5 – 7 һәм 9 пунктларының нигезләмәләре, 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

7. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының (әлеге Закон редакциясендә) 29 статьясындагы 12 һәм 17 пунктлары нигезләмәләре хисаплашулар һәм гарантияләр программаларын, шулай ук бу программаларга үзгәрешләрне Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) белән килештерү өлешендә, 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

8. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының (әлеге Закон редакциясендә) 29 статьясындагы 12 һәм 17 пунктлары нигезләмәләре Татарстан Республикасы (муниципаль берәмлек) тарафыннан хисаплашуны башкару һәм гарантияләр бирү хокукы өлешендә 2021 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 27 сентябрь
№ 71-ТРЗ